ТАТАР АТЫ

Ярдәмче дә, ашатучы да, дус та

> 5

КЫШТАН БӘХЕТ БАР

Кар эретү пунктлары эшсезлектән интекми

> 6

ЯРАТЫП ЯШӘҮ

Татар җәмәгатьчелеге танылган рәссам Зөфәр Гыймаев белән хушлашты

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 24 (28797) | Җомга | 18 февраль | 2022 ел

ВТ

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4 604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

БАРЫБЕР ҖИҢҮЧЕ

КАМИЛӘГӘ ШӘХСИ ЯРЫШТА БЕРЕНЧЕ БУЛЫРГА ИРЕК БИРМӘДЕЛӘР

Нинди генә рекордлар яңартылмасын, быелгы Олимпия Уеннарының тарихка нәрсә белән кереп каласы хәзердән үк билгеле. Пекиндагы ярышлар 15 яшьлек спортчының күз яшьләре, аны бертуктаусыз кыйнаган спорт түрәләренең кыланмышы белән истә калачак. Спортта моңарчы күрелмәгән шау-шуның ни булып бетәсен без әле белмибез. Татар кызы Камилә исә оттырса да бирешмәде.

> 3

Ишетми калмагыз

Бер генә мәртәбә бирелә

Коронавируска каршы антитәнчекләре булганнарга да QR-код бирәчәкләр. Тик аны бары тик бер генә тапкыр алырга мөмкин. Бу хакта Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов хәбәр итте.

QR-кодлы белешмәне 21 февральдән бирә башлаячаклар. Аны алу өчен теләсә кайсы шәхси лабораториядә антитәнчекләргә тест тапшырырга кирәк. Тест нәтиҗәсе «Дәүләт хезмәтләре» порталына эләгәчәк. Өч көн эчендә каралганнан соң, QR-код җибәреләчәк. Ул алты ай гамәлдә булачак.

Дмитрий Лопушов искәрткәнчә, мондый белешмәне бер генә мәртәбә алырга мөмкин. Куллану вакыты чыккач, антитәнчекләргә кабат тикшеренсәгез дә, код бирелмәячәк.

21 февральдән чит ил вакциналарыннан файдаланган кешеләр дә белешмәле булачак. Ул да 6 айга исәпләнгән.

Салым җыю буенча – алтынчы

Татарстан узган елда җыеп алынган салым күләме буенча Россия төбәкләре арасында алтынчы урынга чыккан. Бу хакта «Известия» хәбәр итә. Республикага барлык салым кеременең 3,9 проценты туры килә. Әлеге күрсәткеч буенча аны бары Мәскәү (16,8%), Ханты-Манси (14,4%), Ямал-Ненец (6,7%) автономияле округлары, Санкт-Петербург (5%) һәм Мәскәү өлкәсе (4,8%) узган. Моннан тыш Самара өлкәсе (2,9%), Красноярск (2,8%), Пермь крайлары (2,2%) һәм Иркутск өлкәсе (2,1%) иң күп салым җыюга ирешкән төбәкләр унлыгына кергән. Шул рәвешле беренче ун төбәктә барлык салымнарның 61,5 проценты (17,54 триллион сум) җыелган.

2021 елда Россиядә барлыгы 28,53 триллион сум күләмендә салым җыеп алынган. Бу – 2020 елдагыга (21 триллион сум) караганда 35,8 процентка күбрәк. Шуның 15,88 триллион сумы – федераль бюджетка, 12,65 триллион сумы төбәкләрнең тупланма бюджетларына күчерелгән.

Кар рекорд куя

Татарстанның күп кенә районнарында яуган кар февраль уртасында айлык нормадан ике тапкыр артып киткән. «Татар-информ» агентлыгы, Гидрометеоүзәк мәгълүматларына таянып, шулай дип хәбәр итә. Гыйнварда бөтен республика күләмендә явым-төшем нормадан 1,5–2 тапкыр күбрәк булган. Февральнең беренче сигез көнендә республикада айлык норманың 100–170 проценты чамасы кар яуган. Ягъни айның беренче декадасында республика буенча явым-төшем инде айлык нормага якынлашкан яки аннан артып киткән.

Теманың дәвамы 6 нчы биттә >

ТАШЛАМАСЫЗ БУЛМЫЙ

Һәркем файдалана алсын. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ташламалы ипотека программасын озайтырга тәкъдим итте. Россия Төзелеш министрлыгы белән Россия Дәүләт Советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр мохите» юнәлеше буенча комиссиясенең уртак коллегиясе утырышында республика җитәкчесе шундый фикер белән чыкты.

Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында Россия Президенты Владимир Путинның 2030 елга кадәр илдә елына 120 миллион квадрат метр торак төзи башлау бурычын куйганлыгын искәртте. «Стратегиядә әлегә юнәлештәге иң төп чараларның берсе булып ташламалы ипотека программасы тора. Аннан аерым бер төркем кешеләр генә файдалана алачак дип күздә тотыла. Стратегиядә торакка сорау арттыруның башка ысуллары каралмаган. Шуңа күрә процент ставкасын еллык 7 процент күләмендә саклаган хәлдә барлык категория гражданнар өчен программаның гамәлдә булу вакытын 2024 елга кадәр озайтырга, шулай ук кредит күләмен 3 миллионнан 6 миллион сумга кадәр арттырырга тәкъдим итәбез», – диде Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында. Моннан тыш Татарстан Президенты ташламалы ипотека программасына шәхси торак сатып алу мөмкинлеген дә кертергә тәкъдим итте. «Бу беренчел базарда бәяләр артуны туктатып торырга мөмкинлек бирәчәк», – диде Президент.

Рөстәм Миңнеханов күпфатирлы торак йортларны капиталь төзекләндерү мәсьәләсенә дә тукталды. Аерым алганда, Россиядә иске һәм яңа йортларны капиталь төзекләндерүнең бердәм стандартын кертергә тәкъдим итте ул. «Мәдәни мирас объекты саналган йортларны карап тоту һәм капиталь төзекләндерү белән бәйле сораулар туа. Башкарылган эшләр кыйммәткә төшкәнлектән, милекчеләр җыйган акча гына җитми. Шуңа күрә мәдәни мирас объекты саналган йортларны саклауга карата таләпләрне яңадан карап, аларны капиталь төзекләндерү бәясен бердәм стандартлар белән тигезләргә тәкъдим итәбез», – диде Президент. Моннан тыш республика җитәкчесе капиталь төзекләндерү белән шөгыльләнүче подрядчы оешмаларны сайлау тәртипләрен дә үзгәртергә тәкъдим итте. Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында Россиядә чүп түгүгә дә яңа тарифлар кертергә кирәклеген искәртте.

ИКЕ ЯКНЫ ДА ИШЕТӘСЕ

Узган ел Татарстанның Арбитраж судына гражданнарның бөлгенлеккә төшүе (банкротлыгы) турында 5,7 мең гариза кергән. Бу – 2020 ел белән чагыштырганда 50 процентка күбрәк. Президент Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, мондый эшләрне караганда ике якның да мәнфәгатьләрен истә тотарга кирәк. Аның сүзләренә караганда, банкротлык процедурасын үткәргәндә бурычлы затның дәүләт һәм кредиторлар алдында бурычлары максималь рәвештә үтәлергә тиеш.

«Кызганычка, банкротлаштыру процедурасы алга таба гамәлгә ашыру белән түгел, ә банкротның юкка чыгуы белән тәмамлана. Принципиальрәк эш итәргә кирәк. Мондый фактлар бар. Бу – эш урыннары да, салым базасы мәсьәләсе дә. Шуңа күрә бу хәлнең нилектән килеп чыкканын тикшерергә кирәк. Һәрвакытта да эшмәкәрнең гаебе генә булып чыкмый ул. Монда, минемчә, без дә эшләп бетермибез», – диде ул Арбитраж судының 2021 елгы эшчәнлегенә багышланган утырышта. Президент фикеренчә, эшкуарлык эшчәнлегендә бәхәсләр килеп чыгу куркынычы һәрвакыт бар. Шуңа күрә алар судта үз хокукларының якланасын белеп торырга тиеш. Моңа исә судьяларның үз эшен белеп башкаруы, алар тарафыннан законлы һәм нигезле карарлар чыгару белән генә ирешеп була.

Моннан тыш, Рөстәм Миңнеханов Арбитраж суды вәкилләренә цифрлы технологияләрне киңрәк кулланырга киңәш итте. Президент фикеренчә, бу суд системасының үтемлелеген һәм ачыклыгын арттырырга, суд эшчәнлеге процессын тизләтергә һәм суд аппаратына эшне киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Татарстан Арбитраж судына узган ел 32450 гариза кергән, 28403 эш каралган. Ике күрсәткеч тә алдагы ел белән чагыштырганда күбрәк. Барыннан да бигрәк интеллектуаль милекне яклау, арадашчы килешүләре, административ җаваплылыкка тарту турындагы карарга дәгъва белдерү, электр белән тәэмин итү, милек хокукларын яклауга бәйле эшләр саны арткан.

АВЫЛГА – ӨМЕТ

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Мөслим районына эшлекле сәфәр кылды. Биредә ул капиталь төзекләндерелгәннән соң ачылган балалар сәнгать мәктәбе, авыл хуҗалыгы машиналары производствосы белән танышты, шулай ук район советының хисап сессиясендә катнашты.

tatarstan.ru

Капиталь төзекләндерелгәннән соң балалар сәнгать мәктәбен ачу – мөслимлеләр өчен зур вакыйга. Өч катлы мәктәп бинасы (бүген анда 400гә якын бала укый) дистә елдан артыграк вакыт дәвамында ремонт күрмәгән. Фәрит Мөхәммәтшин фортепиано, җыр, бию, сынлы сәнгать бүлекләре белән танышты.

Шуннан соң Дәүләт Советы Рәисе «Агромастер» җитештерү компаниясе цехында булды. Биредә 250 төрдән артыграк авыл хуҗалыгы машинасы эшләп чыгарыла. Компания Россиядә бу юнәлештә эшләүче иң яхшы 5 предприятие арасына керә. Продукциясе Татарстанда гына түгел, илнең 45 төбәгендә, шулай ук Казахстанда сатыла. «Тулы бер завод! Зур шәһәрдә түгел, ә Мөслимдә. Продукциягә заказ бернинчә елга җитәрлек, эшчеләргә нефтьчеләрнекеннән ким булмаган хезмәт хакы түләнә», – диде Фәрит Мөхәммәтшин предприятие турында.

Район советының хисап сессиясендә 2021 елга йомгак ясалып, 2022 елга планнар билгеләнде.

Башкарма комитет җитәкчесе Альберт Хуҗин чыгышыннан аңлашылганча, район авыл хуҗалыгында җитештерү-икътисади күрсәткечләр буенча узган ел республикада 14 нче урында булган. Соңгы биш ел эчендә авыл хуҗалыгы тулай продукциясе үсеше 197 процент тәшкил иткән. Узган ел гектарыннан 12,4 центнер ашлык җыеп алганнар, 13 мең тонна чамасы сөт, 6,6 мең тонна ит җитештерелгән. Район башлыгы әйтүенчә, Мөслимдә терлекчелек тармагын тагын да үстерергә ниятлиләр.

Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, район аеруча фермерлык хәрәкәтен үстерүгә, агросәнәгать комплексына зур өлеш керткән. Районда гаилә терлекчелек фермалары уңышлы эшли. Дәүләт программасы гамәлгә кертелгәннән бирле Мөслимнән 46 гаилә чама белән 130 миллион сумлык грант откан, шул исәптән узган елда – 1,5 миллион сум. Парламент башлыгы Мөслимдә яшәүчеләрне шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү һәм аларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән максатчан программаларда активрак катнашырга чакырды. «Без шәхси секторда терлек, кош-корт тоткан кешеләргә ярдәм итәчәкбез, ә үзләреннән арткан продукцияне кулланучылар кооперациясе аша сатуны оештырачакбыз», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт Советы Рәисе соңгы сайлау кампаниясе кысасында халыктан җыелган наказларны үтәүгә аерым тукталды. Узган елда республика «юл картасы»на Мөслим районыннан 13 наказ кертелгән. 10ы инде үтәлгән дә. «Районнарыбыз яхшы якка үзгәрә, социаль-мәдәни, сәламәтлек саклау өлкәсе объектлары төзелә, – диде Фәрит Мөхәммәтшин журналистлар белән аралашканда. – Мөслимдә ватанпәрвәрлек, туып-үскән төбәккә мәхәббәт сизелә. Инде бүген үк районның республика авыл хуҗалыгы алдынгылары арасына чыга аласына исәп тотабыз. Быел без районның яңа икътисади күрсәткечләр генә түгел, тормыш сыйфатының сизелерлек яхшыруын да күрәчәкбез».

Укытучы да волейбол уйнаячак

Татарстан Волейбол федерациясенең хисап-сайлау конференциясе 2 мартта узачак. Иҗтимагый оешманың президиумы утырышында шундый карар кабул иттеләр.

Дәүләт Советы Рәисе, федерация президенты Фәрит Мөхәммәтшин утырышта волейболның популярлаша баруын әйтте. «Республикада, профессиональ спорт белән беррәттән, массакүләм волейболны төрле яклап үстерү федерациянең төп максаты булып тора, – диде ул. – «Зенит-Казан» һәм «Динамо-Ак барс» волейбол командаларының зур казанышлары, башка профессиональ, узешчән волейбол командаларының Россия чемпионатында төрле лигаларда һәм ил күләмендәге ярышларда уңышлары, шулай ук предприятиеләр, авыл районнары, студентлар, укучылар һәм ветераннар арасында волейбол буенча лигалар оештырылу дөрес юнәлештә баруыбызны күрсәтте».

Укытучылар да үз араларында волейбол ярышы оештыруны сорый икән. «Волейбол хәрәкәтендә укытучыларның катнашуы әлегә спорт төрен популярлаштыруга ярдәм итәчәк. Шуңа күрә федерациягә яңа проектны оештыру мәсьәләсен кичекмәстән өйрәнергә кирәк», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

БАРЫБЕР ҖИҢҮЧЕ

КАМИЛӘГӘ ШӘХСИ ЯРЫШТА БЕРЕНЧЕ БУЛЫРГА ИРЕК БИРМӘДЕЛӘР

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Әлеге язма бөтенләй башка сүзләр белән башланырга тиеш иде. Инде ничә көн Камилә Вәлиеваның Пекинда күргәннәре турындагы хәбәрләр белән яшәдек. Спорт сөючеләр дә, ярыш һәм медаль белән кызыксынмаганнар да татар кызының боздагы язмышы өчен борчылды. Аңа багышлап шигырьләр яздык, урамнарга рәсемен элдек, кулдан телефонны төшермәдек. Пәнҗешәмбе кичендә олысы да, кечесе дә янә Пекин тарафына борылды. Шәхси ярышның беренче өлешендә дөньяда иң оста фигуралы шуучы икәнен раслаган Камилә Вәлиевадан янә батырлык көттек. Әмма һәр нәрсәнең чиге була. 15 яшьлек кыз бала спортны сәясәткә әверелдергән абый һәм апаларының һөҗүменә, медальне бирәбез-бирмибез, аларны ярышка кертәбез-кертмибез, дип аптыратуларына каршы тора алмады. Егылды, кабат сикерде, еламаска тырышты – әмма соңгы чыгышы җиңүчеләр сафына керә алырлык нәтиҗә бирмәде. Кыйнадылар-кыйнадылар да ахыр чиктә барыбер бозга ектылар. Спортны сөйгәннең дә, сөймәгәннең дә күзеннән яшь чыкты.

Камилә исә, ниһаять, бу сынаудан котылды. Җиңүче булып. Бу вакыйгалардан соң бозга чыга алуы үзе үк җиңү түгелме? «Әгәр: «Олимпиаданың төп герое кем?» – дип сорасагыз, мин: «Камилә!» – дим. Мондый басымга ничек түзмәк кирәк? Тикшерүләр аркасында ярты төн буе баланы йоклатмыйча йөрттеләр. Олы ир-егетләр бала артыннан пычрак сүзләр әйтеп калдылар. Бу чыгышында ул үзе түгел иде, моны барысы да күреп торды.Ниләр генә кичерсә дә, көрәште, тырышты. Әмма аны сындырдылар. Инде баланы тынычлыкта калдырасызмы?! Коточкыч», – диде ике мәртәбә Олимпия призеры булып танылган Ирина Слуцкая ярыш тәмамлангач «Россия 1» каналы эфирында.

Баланы харап иттеләр! Ярыш нәтиҗәләре билгеле булгач, иң еш әйтелгән сүзләр бу. Аны дөньяда иң оста фигуралы шуучы дип атадылар. Хәтта тарихта иң яхшысы дип әйттеләр. Тагын булырмы андый спортчы? Беләсезме, хәзер инде бер дә мөһим түгел. 15 яшьлек кыз үзе ничек кичерер бу вакыйгаларны? Әнә шул мөһим. Тик сәяси мәйданда урын һәм финанс базарында акча бүлешкән абзыйларга монысы кызык түгел. Бу юлы алар спортның иң нәфис төрләреннән берсе булган фигуралы шууга китереп сукты. Корбан итеп бер гаебе булмаган баланы сайладылар.

Иң мөһим сорау: Камиләнең күргәннәре башкалар өчен сабак булырмы? Аңлашыла инде, мондый астыртын көрәш алга таба да дәвам итәчәк. Ул көрәштә спорт төрләре түгел, кызганыч, бөтен тормышын җиңүгә багышлаган егетләр һәм кызлар харап була. Әлегә әйткәләш бара, ә җавап бирүче юк. Җавапны исә безнең якташлардан да көтәбез. Анна белән Александра медаль откач, бер-берегезне уздыра-уздыра ничек мактанасыз, мондый хурлыклы хәлләр кабат килеп чыкмасын, Камиләләр еламасын өчен дә шулай тырышсагыз иде. Алайса, киләсе Олимпиадаларга кем барыр?

Илнар ХӘСНУЛЛИН

СӘЙДӘ МӨХӘММӘТҖАНОВА:

«МЕДАЛЬ БИРМӘСӘЛӘР ДӘ, МИНЕМ ӨЧЕН УЛ БАРЫБЕР ЧЕМПИОН!»

Танылган яшь җырчы Сәйдә Мөхәммәтҗанова әйтүенчә, ул Олимпия Уеннарында чыгыш ясаучы Камилә Вәлиевага карата әйтелгән гаепләү сүзләренә ышанмый. «Барлык җиңүләренә дә үз көче белән ирешкән кыз ул», – ди җырчы кыз спортчы дусты турында.

– Камилә тирәсендә килеп чыккан шау-шу көтелмәгән хәл булды. Спортчы Олимпиадага бәйрәмгә килгән кебек килә. Ә монда шундый хәбәр тарала! Ниләр кичергәнен Камилә үзе генә белә инде. Без исә аңа ярдәм итәргә, теләктәшлек күрсәтергә тиеш! Аның дару кулланганын күз алдына да китерә алмыйм. Ике генә мәртәбә очрашсам да, Камиләнең нинди кеше икәнен күрдем мин. Бөтен уңышларына үзе ирешкән, мондый җиңүләр яулау өчен бернинди препарат та булыша алмый. Әлеге шу-шу килеп чыгуның төрле сәбәпләре, шул исәптән сәясәт белән бәйле булганнары да бардыр. Бу хәбәрләргә ышанмыйм, ышанмаячакмын да. Медаль бирмәсәләр дә, минем өчен Камилә барыбер чемпион булып калачак, – ди Сәйдә. – Соңгы арада аның белән аралашканым булмады. Әмма мин дустыма «Инстаграм» аша мөрәҗәгать юлладым. Беркемнән дә курыкмаска киңәш иттем, бернинди дә гаебе юклыгын, илдәге бар кешенең аның ягында булуын, җан атуыбызны, яратуыбызны әйттем. Бу сүзләрнең аңа барып җиткәнен беләм.

Җырчы кыз якташыбызның чыгышын бик дулкынланып караган. «Башкалар кебек, мин дә туры эфирда күзәттем. Ул вакытта студиядә җыр яздыра идек. Бөтен эшне читкә куеп, Камилә өчен җан аттым. Бик дулкынландым, йөрәгем дөп-дөп типте, уч төпләрем тирләп чыкты. Мин генә түгел, башкалар да шулай дулкынланган икән», – ди Сәйдә.

Җырчы белән спортчының дуслыгы моннан берничә ел элек башланган.

– 2018 елда Мәскәү беренчелегендә Камилә кыска программада мин гарәп телендә башкарган «Йә илаһи» җырына чыгыш ясаган икән. Бу хәбәрне алгач сөендем, әлбәттә. Ул вакытта әле ул танылып кына килүче спортчы иде. «Инстаграм»дагы дуслары да күп түгел иде. «Матур шуасың», – дип яздым. Ул рәхмәт әйтте. Шуннан аралашып киттек, – дип искә ала Сәйдә. – Күңелендә татарлык бар Камиләнең. Казанга килгәч, күрештек. Әле дә истә: сәгать кичке 4тә Муса Җәлил һәйкәле янында очрашабыз, дип сүз куештык. Аңа бүләк алам дип соңга калдым. Ә ул, спортчы буларак, вакытында килгән, бүләк тә алырга өлгергән.

КАМИЛӘ ВӘЛИЕВАНЫҢ ТУГАННАРЫ:

«БӨТЕН АВЫЛЫБЫЗ БЕЛӘН КӨЧ БИРЕП ТОРАБЫЗ»

Апас районындагы Тәүгелде авылы халкы Камилә өчен аеруча борчылды бу көннәрдә. Шулай булмый ни! Алар спортчы кызны якташлары дип саный. Камиләнең бабасы Әнвәр Вәлиев Тәүгелдедә туып-үскән. Авылда Әнвәр абыйның апасы Нәзимә белән энесе Гомәр яши.

– Бу көннәрдә бөтен авыл гөр килә. Урамга чыксак, бөтен кешенең телендә – Камилә. Үзебезнеке бит, авылныкы. Бик горурланабыз! Безнең авыл бердәм бит ул. Әнвәр абыйны да белмәгән кеше юк. Кызганыч, 47 яшендә үлеп китте ул. Исән булса, сөенеченнән нишләмәс иде?! Камиләнең әбисе исән-сау, Казанда яши. Бүген бөтен дөнья сокланган баланы 3 яшьлек чагында авылга да алып кайтканнар иде. Кечкенә генә, ал төстәге күлмәк кигән, сөеп туя алмаслык кызчык булып истә калган, – дип сөйли Гомәр абыйның хатыны Әлфинур апа Зиннәтуллина. – Әлбәттә инде, бик борчылдык Камилә тирәсендә килеп чыккан шау-шуга. Кызганабыз, кечкенә генә кызчык бит! Юк инде, наным, 15 яшьлек бала ничек тыелган дару эчсен? Шулай да, барысы да ачыкланыр, гаделлек җиңәр дип өметләнәбез.

Татар театрын японнар төзи

Үткен, кискен, максатчан. Камал театрының яңа бинасы өчен җаваплы архитекторлар үз проектларын ясаганда татарларның нәкъ менә шушы сыйфатларыннан илһамланган. Һади Такташ һәм Нурсолтан Назарбаев урамнары киселешендә салыначак бинаның үзенчәлекләре аны татар мәдәниятенең яңа үзәге итә алырмы?

Һәрхәлдә, төп максатларның берсе шул иде. Шуны истә тотып, 2021 елның июлендә архитектура концепциясен эшләүгә ачык халыкара конкурс игълан ителде. Проект халыкара кызыксыну уятты дип әйтсәк тә хак булыр. Ник дигәндә, 537 гариза теркәлгән булган, алардан сигезе финалга чыккан. Ниһаять, сигез проект арасыннан җиңүче сайлап алдылар.

Шунысын да искәртик: 16 февральдә финалга чыккан сигез катнашучының проектлары белән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов танышты. Жюри әгъзалары сүзләренә караганда, исемнәре бөтен дөньяга мәгълүм булган катнашучылар арасыннан иң-иңнәрен сайлап алу җиңелләрдән булмаган. Сүз уңаеннан, республика җитәкчесе белән Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры әлеге бәйгене башлап җибәрүчеләр дә булып тора.

Җиңүченең исемен Казан мэры, конкурсның жюри рәисе Илсур Метшин игълан итте. «Фикер алышу иртәнге якта гына тәмамланды. Гаять катлаулы булса да, әлеге конкурс чын архитектура бәйрәменә әйләнде. Жюри әгъзалары бик озак уртак фикергә килә алмады, чөнки проектларның барысы да искиткеч иде. Нәтиҗәдә финалга чыккан өч бюро арасыннан 0,7 балл өстенлек белән Япониянең «Kengo Kuma & Associate», Германиядән «Werner Sobek AG» компанияләре һәм Казаннан Герман Бакулинның шәхси остаханәсен берләштерүче Мәскәүнең «Wowhaus» бюросы җиңде», – диде ул.

Булачак бинаның проекты турында берничә сүз. Авторлар татар халкының үзенчәлекләрен бик яхшылап өйрәнүләрен искәртте. Бина очлы, уксыман катлы-катлы түбәсе белән аерылып торачак. Архитекторлар моны татарларда укның максатчанлык символы булуы белән аңлата. Шәһәр архитектурасында да мондый символ күп кулланыла икән. Моннан тыш, бина Камал театры янәшәсендәге Кабан күле өстен каплаган «бозлы чәчкә»ләрне хәтерләтәчәк. Татар орнаментларын куллану турында да онытмаганнар.

Ләкин жюри әгъзаларының кайберләре әлеге конкурста бөтенләй башка катнашучылар җиңәр дип уйлаган. Татарстан Президенты ярдәмчесе Наталия Фишман-Бекмамбетова сүзләренчә, нәтиҗәдә гаделлекне саклап калу – иң дөрес карар. «Без «БЕСПОУК» консорциумы җиңәр дип уйладык. Ләкин тавышларны санаганнан соң, беренче урынга башка архитекторлар лаек дип табылды. Һәм бу дөрес тә. Без башкаларның да фикерен хөрмәт итәргә тиеш. Беләсезме, мин бүген Казан өчен горурланып утырам. Бу шәһәр дөнья күләмендә танылган архитектор арасыннан иң-иңнәрен сайлау бәхетенә ия булды», – диде Фишман-Бекмамбетова.

Әлеге конкурс безнең мәдәниятне, тарихны, традицияләрне популярлаштыручы мөһим бер вакыйгага булып истә калачак. Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова әнә шул фикердә. «Мондый киеренке вазгыятьтә дә шундый зур эш башкара алырбыз дип башыма да килмәгән иде. Без чыннан да киләчәк өчен әйтеп бетергесез зур мәдәни мирас калдырачакбыз», – диде ул.

Туй үпкәсез булмый. Камал театрының баш режиссеры үз чыгышын шул сүзләрдән башлады. «Мин дә башка проект җиңәр дип уйлаган идем, нәтиҗәләрне монда килгәч кенә белдем. Уникаль тәҗрибә булды бу. Урыны-урыны белән театраль тамашага охшаган иде. Оештыручыларның барысына да бу тарихи вакыйга өчен рәхмәт әйтәсем килә. Безне зур җаваплылык көтә. Тәэдек тә бетте түгел, анда әле эшлисе дә булачак. Бина гына да түгел, без дә үзгәрербез кебек. Үзгәрербез, әмма татар театры әле озак яшәр», – диде ул матбугат очрашуында.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

БӘЛЛҮР СӘҮДӘСЕ

Соңгы көннәрдә финанс базарларының яру пычкысы кебек бер өскә, бер аска йөреп торганын, доллар курсының сикереп уйнавын күрә торгансыздыр. Кемнәрдер бу уенда бик яхшы кул җылыта, кәгазьләр кыйммәтләнгәндә саталар, куыклар шиңеп, түнтәрелеш булгач, сатып алалар. Дөрес, моның өчен яшерен мәгълүматка – инсайдер хәбәрләренә ия булырга кирәк.

Күреп торасыздыр бит инде: биржа мәтәлчеге югары җитәкчелекнең белдерүләренә, гаскәрләрнең фронт сызыгына таба яисә кире якка хәрәкәтенә бәйле. Шуңа күрә биржа уеннарында май катламы булдырып симерим дисәң, югары сәяси җитәкчелек белән тыгыз элемтәдә булу кирәк. Кара халык исә кыйммәтләнгәндә сатып алып, бәя төшә башлагач сатып, гел кәкре каен терәтә андый чакларда. «Төркем» психологиясе паникага бик тиз бирелүчән бит ул. Чын спекулянтлар исә алай кыланмый, алар биржа тетрәнүләрен үзләре китереп чыгара, сәяси уеннар белән идарә итәләр. Зур сәясәтчеләрнең украин кризисы кебек конфликтларны махсус оештырып, аннан мул дивидендлар, ягъни табыш алуы турында фикер еш ишетелә. Конфликт бар ул үзе, әмма ул ясалма каршылык, ул каршылыкны мәйданга чыгарып, зур сәясәтчеләр үзләренә сәяси очколар туплый һәм финанс дивидендлары сава. Ил җитәкчеләре белән тыгыз бәйләнгән олигархик капитал ияләре тиктомалдан гына акча яңгыры астында калмый бит. Кризис тирәнәйгән саен миллиардерлар хисабында акча арта.

Язганнарның буш сүзләр генә түгеллеген совет чоры тарихындагы бер кызыклы мисал белән дәлилләп идем мин. Дөресен генә әйткәндә, бу язманы 1992 елда Ельцин имза салган «Сәүдә иреге турында»гы указның утыз еллык юбилеена багышларга уйлаган идем. Моннан утыз ел элек базарга куәтү турында карар кабул ителде, бәяләр ирекккә җибәрелде, әмма кибет киштәләре һаман да шыр иде әле. Кремльдә ул чакта яхшы аңлыйлар: кыйммәт бәядән булса да товар, бигрәк тә азык-төлек пәйда булмаса, алдангган халык баш күтәрергә мөмкин. Ул көннәрдә, имеш, хәзерге оборона министры Сергей Шойгу (ул чакта Гадәттән тыш хәлләр комитеты белән җитәкчелек итә): «Безгә халыкның стихияле баш күтәрүләре белән шөгыльләнүне тапшыруларыннан Ходай саклаcын», – дип әйткән. «Сәүдә иреге турында»гы указга имза салыну белән, икенче көнне үк кулларына сигарет кабы, бәйләнгән оекбаш, хәтта аракы шешәсе тоткан халык урамга чыгып сәүдә итәргә кереште. Нәрсә белән сәүдә итсәң дә, кайда сәүдә итсәң дә, рөхсәт иде чөнки. Бары тик машина юлына гына чыгып басма. Инженерлар, укытучылар, фән докторлары берничә көн эчендә «торгаш»ларга һәм спекулянтларга әйләнде. Шул чакта спекулянт сүзен алыпсатар дип татарчага аудардылар. Әмма бу сүзләр синонимнар түгел үзе. «Скупить» дигән сүздән алынган спекулянт сүзе колоритлырак һәм нечкәрәк мәгънәләргә ия ул. Спекулянт булу өчен бер җирдән сатып алып, икенче урынга илтеп сату гына җитми, комсыз рәвештә зур табыш алу өчен шартлар тудырырга яисә тормыш алга китереп куйган шартларны оста файдалана белергә кирәк. Ә товар ташып, аларга бәя өстәп сатучылар – сәүдәгәрләр алар, алыпсатар шул сүзнең ясалма бер неологизмы гына. Менә күз алдына китерегез: сәүдәгәрләр булмаса, иртәгә үк кытлык һәм ачлык башланачак. Спекулянт исә – менә шул кытлыкны, булдыра алса, ачлыкны ук оештырып, гигант табышлар алу белән шөгыльләнүче. Коронавирус пандемиясе башлануга, менә шул спекулянтлар мәйданга чыкты да инде, күп кенә товарларга бәянең ике-биш тапкыр артуы – шуларның вазгыятьне файдалануы һәм формалаштыруы нәтиҗәсе дә.

Спекуляция исә совет чорында бик киң таралган иде, чөнки кытлык бар, сорыкорт катлау шундый шартларда вирус кебек үрчи дә инде ул. Бу юлларның авторы яшьләргә гел әйтә: совет чорында бай булу өчен мөмкинлекләр зуррак иде, аны совет кешеләре файдалана гына белмәде. Законны бозмыйча да әллә никадәр зур акчалар эшләп була иде ул чакта. Ышанмасагыз, татар совет классик язучысы Әмирхан Еникинең «Әзер хикәя» дигән хикәясен укып карагыз. Язгы якта терлекләргә ашатырга бер уч печәне, фуражы булмаган колхоз председателенең берничә көн эчендә уңышлы алыш-биреш итеп (бернинди товары булмаган килеш), хуҗалык кассасына утыз биш мең сум акча (иске совет акчасы белән гаҗәп зур сумма) эшләп алуы һәм терлек азыгы да юнәтүе турында ул хикәя. Әмма хосусый сәүдә нык тыелган иде ул чакта. Оренбург өлкәсенә барып кәҗә мамыгы алып кайтып саткан өчен хөкем ителгән авылдашлары, свитер саткан өчен вуздан куылган курсташлары бар иде бу юллар авторының. Совет кешесе андый сәүдәгәрләрне куралмый һәм спекулянтлар дип атый иде.

Чын спекулянтлар да очраштыргалый иде ул чакта. Шуларның технологиясе хәзерге биржа спекуляцияләрендә кулланыла да инде. Александр Панкратов-Черный атлы актер һәм кинорежиссер бар бит әле. Шул яшьлектә оештырган бер спекуляция турында сөйлим сезгә. ВГИКта укыганда 38 сум стипендия алып, 500 сумга җиткән бурычка батуы хакында искә ала ул. Шул чакта совет илендә бәллүргә бәя кискен күтәреләчәге хакында имеш-мимешләр тарала. Булачак артист һәм режиссер Белоногов дигән икенче бер талант белән бергәләп зур бер махинация оештырып ташлыйлар икесе шул чакта. Алар курсташ кызларны һәм егетләрне ЗАГСка ялган гариза язарга күндерәләр. Шундый гаризаң булса, Никахлашу сараена чакыру кәгазе эшләтеп була. Шул кәгазь белән прокатка бәллүр савыт-саба алып тору мөмкинлеге туа. Әле тагын арзанга алтын балдаклар да ала аласың. Егетләр беренче мөмкинлектән файдаланалар. Прокат пунктына барып, туйга дип күп итеп бәллүр савытлар җыялар һәм бер грузинга аларның бәясен алты тапкыр арттырып саталар. Ун сумлык фужер өчен теге алтмыш сум түли. Прокат пунктына грузин алмаган савыт-саба гына кире илтелә. «Калганнары туйда ватылды», – дип акланалар һәм сервизларның үзкыйммәтен генә каплата торган тиенлек штрафлар түлиләр. Бер атна эчендә берничә мең сум акча эшләп алуларын әйтә артист, әҗәтләрне түләгәч, курсташларга җылы пальто, аяк киемнәре сатып алуларын, акчаның хәтта мотоциклга да җитәрлек калуын искә ала. Акчаны эчеп бетерү сәбәпле, соңгысы алынмый кала, билгеле. Совет чоры өчен баш китәрлек җинаять иде бу афера. Егетләргә җинаять эше ачыла. Әмма боларга бәхет елмая. Атаклы совет режиссеры, Сталин һәм СССРның Дәүләт премияләре лауреаты Борис Волчек илнең эчке эшләр министры Щелоковка (алар дуслар булалар) шалтыратып, булачак даһиларны коткарып кала.

Хәзерге биржа сәүдәсендә дә менә шундый бәллүр сату ысулларына охшаган технологияләр кулланыла. Бирердә, әлбәттә, иң мөһиме бәянең кайчан күпмегә күтәреләчәге, күпмегә төшәчәге турында мәгълүматка ия булу. Бу исә югары җитәкчелеккә якын торганда гына мөмкин. Миллиардлар шулай эшләнә: бәя күтәрелгәндә сатасың, төшкәндә аласың. Лондонда тиктомалдан гына украин конфликтына бәйле рәвештә олигархларның малын конфискацияләү белән янамыйлар бит. Конфликтлар һәм кризислар зур капитал ияләре мәнфәгатендә оештырыла һәм алар бөтен дөнья халыклары бөлгенлеккә төшкәндә мал арттыралар. Бу хәзерге глобаль капитализм өчен табигый һәм законлы булып санала. Аның өчен хөкем итмиләр.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ИР КАНАТЫ, АВЫЛ САКЧЫСЫ

«Татар» сүзенең тамырында ук «ат» сүзе бар. Ә тамырлардан, тарихтан баш тартырга ярамый ул. Болай да бит гореф-гадәт дигәннәрен тарих тузанында югалтырга күп сорамыйбыз. Ни өчен татар – атлы, ә ат татарлы булырга тиеш? Борынгыдан килгән ат тоту шөгылен кире кайтару мөмкин һәм кирәкме?

leninogorsk.tatarstan.ru

Кайтарырга, сакларга, югалтмаска!

«Хөрмәтлеләрем». Фәрит Нәбиуллин атларына шулай дип дәшә. Хөрмәткә ни өчен лаек булганнарын да аңлата. Анысы турында соңрак әйтә әле ул. Иң элек – хыялланудан башлыйк.

Гомумән, Лениногорск районында яшәүче бу кеше турында республикада ишетмәгән кеше бармы икән ул? Чын атсөяр, чын ватанпәрвәр. Кыска хәтерне яңартыр өчен искәртик: Фәрит Нәбиуллинны нәселле татар атлары токымын торгызучы, кышын 400 аттан «Алга» сүзен ясап тездерүче, милләт дип янып йөрүче, тарих белән кызыксынучы дип белерсез. Ә милләт, авыл, татар язмышының атлардан аерылгысыз булуын яхшы аңлый ул.

– Хыялдан башланган эшем бу минем, – ди хәзерге вакытта 500ләп нәселле ат тоткан әңгәмәдәшебез. – 2010 елда тотынган идем, шул ук елны Башкортстан, Чиләбедән беренче атларны алып кайттым, ике елдан аларның санын 70кә җиткердем. Авылда үскән бала бит мин. Ул чакта атсыз авылны күз алдына китерү мөмкинме? Бабам да ат тоткан, мине өч яшемдә атка ул утыртты да инде. Атка мәхәббәт минем белән бергә тугандыр, дим. Ул минем балаларыма да күчте.

Кайтарырга, сакларга, югалтмаска! Халыкның татар атлары каршындагы төп бурычы хәзер шул дип саный Фәрит Нәбиуллин. Аныңча, ат тоту, үрчетү культурасы халыкта беркайчан да бетмәгән. Кайтара башладылар бит инде, хәзер күбрәк таратырга, дөньяга танытырга вакыт.

– Учак белән чагыштырып кара. Пыскып торса, чыбык ташлыйсың да, яныпкитә ул. Менә безнең татар аты дигән токымны кайтару да учакка утын өстәү булды, – ди атлар хуҗасы.

«Ат тоту – чыгымлы» дигән сүзләрне дә кире кага Фәрит Нәбиуллин.

– Табигать елдан-ел үзгәрә. Күпме фермер сыерларын сатты. Ни өчен? Азык җитми бит! Безнең көньяк-көнчыгыш районнарда таулар, әзме-күпме үлән үсә, кабыклар да бар. Аны сыер ашый алмый, билгеле. Безнең атлар исә табигатькә шулкадәр яраклашкан! Алар көне-төне тау битендә. Теләсә нинди табигать шартларына чыдам, азыкка талымсыз татар атлары. Бу мөмкинлекне аларны үрчетү өчен файдаланырга кирәк. Сыердан кеше бизеп бара, асрарга авыр, файдасы юк. Без атларны ике ай гына – февральдән апрель уртасына кадәр генә ашатабыз бит! Сыерны елына ничә ай ашатасың? Май уртасыннан октябрь уртасына кадәр ашый ул. Ә ат – ике ай. Аерма бармы? – дип аңлата эшмәкәр.

Атның даны – егет кулында, ди халык та. Әмма салаларда ат җигә, иярли алган егетләр бармак белән санарлык булса да калдымы икән соң?

– Гомумән, юк алар, – дип борчыла Фәрит Нәбиуллин да. – Авылларда ат та табып булмый хәзер. Без моны үзгәртергә тиеш, ат тотуның мөһимлеген үз халкыбызга җиткерергә тиешбез. Атыбызны күтәргәч, халкыбызны да күтәрәбез дигән сүз бит! Миннән: «Татарның аты булганмыни?» – дип көлгәннәр иде баштарак. Бернигә дә карамадым. Үз эшемне эшләдем, алга бардым. Менә бит: атларыбыз да булды, дәвамчым да бар – улым атлар турында миннән күбрәк тә белә. Нәселле татар атлары токымы торгызылды. Татар халкы үз атын кайтарды. Ат милләтебезне һәм авылларыбызны саклап калучы корал була ала, бу 100 процент шулай. Ни өчен? Менә «Аударыш», борынгы «Бәйге» уеннарын яңарттык. Аны һәр Сабан туенда үткәрергә кирәк! Чемпионатлар булырга тиеш. Атлар белән походларга йөрергә, әйтик, Казаннан кузгалып, Болгарга кадәр барырга кирәк. Бу хакта күп әйттем инде, колагына элүче күренми. Ниндидер курку бармы? Үз-үзеңә ышаныч юкмы? Авылны агрохолдинглар гына түгел, милли традицияләр дә саклый. Ярышлар, ат чабышлары булсын. Башка төр атларны танытырга кирәкми. Үзебезнеке бар! Авыл кешесе өчен ат – чын ярдәмче. «Хөрмәтлеләрем» – мин атларыма шулай дип дәшәм. Алар хөрмәткә лаек та! Алар табигатькә яраклашкан, аның белән берботен. Без ул – атларга хыянәт итүчеләр. Атлар күзлегеннән караганда, сатылган халык. Ат – безнең дус. Ул безгә хыянәт итмәячәк, сатмаячак. Хәзер инде шундый заманда яшибез: кеше кешене күралмый. Ат андый түгел!

Фәрит Нәбиуллинның атлар белән берлектә чынга ашырасы матур хыяллары да бар икән әле.

– 21 майда Оренбургның Татар Каргалысыннан Биләргә, Биләрдән Болгарга барырга җыенабыз. Татар атлары, дөяләр белән изге җиребезгә керәчәкбез. Бик матур күренеш булырга тиеш ул. Борынгы матур киемнәр киеп, гаскәриләр кебек! Хыялланып, зур планнар корып, бәләкәй авылларда да яшәп була. Зур шәһәрдә: «Ник яшим икән?» – дип тормыш итәргә дә була, – ди ул.



ТАТАР АТЫ – УЛ...

- 400–450 кг тере авырлыкта
- биек түгел, 135–140 см
- куе-тыгыз йонлы
- 7–8 сәгать эчендә 100 чакрым (аннан да күбрәк!) юлны бертуктаусыз уза ала
- түзем, көчле

«Атлы җирдә авыл бетмәс»

– Ата-бабаларыбыз атсыз яши алмаган. Ат ярдәмче, ашатучы, хезмәттәш тә, дус та булган. Яңа гасырга атлавыбыз атка карата мөнәсәбәтне үзгәртте. Хәзер кайсы гына авылга кермә, ат табуы икеле, аны техника алмаштыра, – ди Башкортстандагы Туймазы районының Түбәнәк авылыннан Фәнир Галимов. Баксаң, күпләп атлар асрармын, дип хыялланган кеше дә булмаган ул. Колхоз таралгач, андагы 20 атны сатып алган, баш санын берничә йөзгә арттырган инде хәзер. Нәселле булгач, төрле төбәкләрдән сатып алырга дип киләләр икән. Биш еллап кымыз ясау белән шөгыльләнәләр. Малкайлар арасында йөк атлары да, татар атлары да бар.

– Йөк атлары акрын, юаш. Татар атлары, татарның үзе кук, горур. Аларда да безнең кан агадыр, дим. Чабышкы атлар асрыйлар, хобби буларак кына булса да ат тоталар икән, бу начар түгел. Атлы җирдә авыл бетмәячәк, – ди Фәнир Галимов.

Борчыган мәсьәлә

Арчаның Яңасала авылыннан Айрат Сафин татар атларын тотмый. Аның хуҗалыгында чиста токымлы 10лап чабышкы ат асрыйлар. Аның сүзләренчә, халыкның атка мәхәббәтен кайтару өчен аерым бер ат төрен үрчетү, күрсәтү генә җитми. Сүз уңаеннан, атка ит буларак кына караган кеше – атчы түгел дип саный әңгәмәдәш.

– Мине менә ни борчый: килер бер көн, Сабантуйларда ат чабышлары булмас. Мондый чараны мин бәйрәмгә саный да алмыйм. Күп авылларда ат чабышлары юк та... Хәзер авыл малайлары ат җигү, тугару, су эчертергә алып төшү, атка атлану, бәрәңге утырту кебек нәрсәләрне бөтенләй белми, – дип кайгыра Айрат Сафин. – Чабышлар өчен 20 еллап ат үстерәбез. Нәтиҗәләребез дә бар. Үз улларым атта чапты, хәзер әйбәт итеп әзерлиләр, киләчәктә оныкларым да, бәлки, җайдак булыр.

Татарстандагы атчыларның җан авазын да җиткерде әңгәмәдәшебез.

– Республикада искиткеч инфраструктуралы ипподромыбыз бар. Шунысы кызганыч: анда безнең ише гади атчыларга урын юк. Ягъни безнең кесәбез күтәрә торган түгел. Чабыш аты спортчы кебек инде ул. Аңа да күнекмәләр кирәк. Кышын без аларны басуларда чаптырырга мәҗбүр. Россиянең җылырак төбәкләреннән килгән атлар белән ярышу безнекеләргә авыррак бирелә. Алар бит соңгы ике айда гына юньләп шөгыльләнә ала. Бу зарыбызны ишетсеннәр иде, – ди ул. – Ярышлардагы приз фонды да әллә ни түгел инде. Авылдан килгән атларга күп түгел ул. Авыл баласының тәгәрмәченә таяк тыгу кебек бу... Шунысы да бар: миңа еш кына район, хуҗалык җитәкчеләре аларның җирлеге исеменнән чапсын дип ярышта катнашу өчен ат сорап мөрәҗәгать итәләр. Ник алар мондый хәлгә килеп җитә соң? Үзләрендә мөмкинлек тудырып булмыймы? Бу җәһәттән Балтач районы яхшы шөгыльләнә. Һәр районда ат спорты мәктәпләре булсын иде дип телим. Ат сөйгән, ат янында йөргәннәрнең күңелендә әшәкелеккә урын калмый. «Ат җене кагылган», – диләр. Булсын, башкасы – начар гадәтләр җене кагылмаган бит.

Татар аты асрап кына татарны кире атка кайтару мөмкин түгел дигән фикердә Айрат Сафин. «Булсын ул, әмма әйтүемчә, бу гына җитми. Атның исемендә түгел эш, бу малның һәр районда, хуҗалыкта булуында», – ди ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Бу – кызык!

Татар атларын торгызу турында Казанның мөңьеллыгыннан соң уйлана башлыйлар. Охшаш токымнарны эзләү эше Татарстан, Башкортстан авылларында, Казахстан, Алтай, Оренбург һәм Чиләбе өлкәләрендә бара. 2019 елның февралендә татар атлары токым буларак рәсми рәвештә теркәлде. Дөньяда атларның 430лап токымы исәпләнә.

ЯЗНЫ КӨТӘСЕ ТҮГЕЛ

Быел кышның бәхете булды. Кардан диюебез инде. Авылларда да, шәһәр урамнарында да биек булып өелгән кар өемнәре күзгә ташлана. Бу күренеш авыл хуҗалыгы өчен сөенечле булса да, шәһәрдәгеләргә шактый мәшәкать тудыра. Шунлыктан кар эретү пунктларында да эшсезлектән тилмермиләр быел. Эшләре өч тапкыр арткан. Алып килгән карны эретеп өлгермиләр, пункт янында озын чират хасил була. «ВТ» хәбәрчесе Казандагы кар эретү пунктларының берсендә булып, барысын да үзе күреп кайтты.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шәһәр карының 60 проценты пунктта эри

Татарстанда, Казаннан кала, кар эретү пунктлары булу-булмау турында мәгълүмат ала алмадык. Республика Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы да хәбәрдар түгел булып чыкты.

– Пунктлар булган очракта да, шәхси яки район карамагында гына булырга мөмкин, – диделәр министрлыкның матбугат үзәгендә.

Башкалада исә җиде кар эретү пункты бар. Аларның барысында бергә 11 камера эшли. Бер камера тәүлегенә 1500 куб метр кардан чистарта. Димәк, җиде камера барысы бергә тәүлегенә 7 мең тонна кардан чистарта дигән сүз. Исегезгә төшерәбез: Казанда беренче кар эретү пункты Портовая урамында 2007 елда төзелгән иде. Соңгысы 2020 елда Гадел Кутуй урамында ачылды. Без барган пункт иң зурларыннан санала. Аларның зурлыклары камера санына карап кына аерыла. Камера дигәндә, җирдәге тимер рәшәткәләрне күз алдына китерергә кирәк.

Карны 5 чакрым ераклыктан артык ташып йөрмәс өчен эретү пунктлары Казанның төрле районнарында урнашкан. Бу эшне дә җиңеләйтә, вакытны да янга калдыра. Төп авырлык исә Җиңү проспекты, Несмелов һәм Портовая урамнарындагы пунктларга төшә.

Казан башкарма комитетының эчке төзекләндерү комитеты бүлек башлыгы Марсель Әхмәтҗанов әйтүенчә, шәһәр урамнарыннан чыгарылган карның 60 процентын кар эретү пунктларына алып киләләр. Калганнарын вакытлыча саклау өчен, билгеләп куелган махсус урыннарга ташыйлар. Пунктларында эшләр кимегәч, аларга да чират җитәчәк.

– Быел кар күп яуды. Урамнарны кардан һәм боздан чистарту тиешле тәртиптә алып барыла. Бүгенгә әлеге эшләргә 563 эшче һәм 391 техника җәлеп ителде. Кызганыч, төп проблема эшчеләр һәм машина йөртүчеләр җитмәвә. Февральдә 39,5 мм күләмендә кар яуды. Бу инде айлык нормадан 28 миллиметрга артып киткән дигән сүз. Гадәттә, кышның соңгы һәм язның беренче айларында кар болай да күп ява торган иде. Әлеге кышкы сезонда Казан урамнарыннан 830 мең тонна кар чыгарылды. Бу узган елның шушы чоры белән чагыштырганда 17 процентка күбрәк, – ди Марсель Әхмәтҗанов.

Белгеч сүзләренә караганда, кар эретү пунктларының эшләре өч тапкыр арткан. Эшчеләр тәүлек буе эшләсәләр дә, карны ташып һәм эретеп өлгермиләр. Шәһәрдәге барлык карны вакытында чыгарып бетерү һәм пунктларда чиратлар барлыкка килмәсен өчен башкалага тагын 12 пункт кирәк. Казанда әлегә дүрт камера төзергә планлаштырыла.

– Ул шәһәр үзәгендәге урамнарны кардан вакытында чистартырга ярдәм итәр иде. Шулай ук су чыксын өчен урам канализациясе станцияләрен дә реконструкцияләү кирәк, – ди шәһәр җитәкчелеге.

Карны канализация сулары эретә

Без барып күргән кар эретү пункты Җиңү проспектында урнашкан. «Мега» һәм «Южный» сәүдә нокталары арасындагы әлеге объектны ерактан ук чамаларга мөмкин. Чөнки монда кар төягән «КамАЗ»лардан җыелган чират берничә чакрымга сузылган иде. Дөресен әйткәндә, эш тәртибен бераз башкачарак итеп күзаллаган идем. Чынлыкта кар эретү пункты менә мондый тәртиптә эшли.

Машиналар карны шәһәрнең төрле урыннарыннан алып килә. Пункт эчендә аны рәшәткә өстенә бушаталар. Кар арасыннан чыккан эре чүп-чар өстә кала, ә карны трактор эттергече белән рәшәткә арасына этеп төшерәләр. Рәшәткә астында канализациянең берничә фильтр аша чистартылган җылы сулары ага. Аның температурасы якынча 18–20 градусны тәшкил итә. Карны нәкъ менә шул сулар эретә дә инде. Суны шәһәрнең чистарту корылмаларына җибәрәләр.

Эретү пунктында тау-тау булып кар өелгән. Кар азрак яуганда алары булмый икән. Пункт янында чакрымнарга сузылган машина чираты да – гадәттән тыш күренеш, дип аңлаттылар безгә.

Бер машина йөртүче белән дә сөйләшеп алырга җай чыкты. Үзен Марат дип таныштырган абый Яшел Үзән районының бер авылыннан эшкә килеп йөри икән.

– Быел кар бик күп. Узган елларда болай булганын хәтерләмим. Карны төрле урыннардан ташыйбыз. Бүген мин, мәсәлән, «Весна» торак комплексыннан китерәм, – диде ул.

«Карны тиеш булмаган урыннарга да илтеп түгәсезме?» – дигән соравыма җавап итеп:

– Ә кая куеп бетерәсең аны? Күп бит ул, – диде. – Җитмәсә, пунктта чират торып күпме вакыт сарыф итәлә. Тагын берничә пункт һичшиксез кирәк. Анысы – бер бәла. Икенчесе – юлларда теләсә ничек ташлап калдырылган машиналар. Менә шулар эшне бик нык тоткарлый һәм өстәмә мәшәкатьләр китереп чыгара. Машина йөртүчеләрне дә аңлыйбыз, ләкин алар урамнарны кардан чистартучыларга авырлык китереп чыгара.

Кемгә – чишелеш, кемгә – проблема

Машина йөртүчегә биргән соравым юктан гына барлыкка килмәде, чөнки соңгы көннәрдә тиеш булмаган урыннарга кар өю очраклары тагын да арткан. Республиканың Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы безгә тәкъдим иткән мәгълүматлар буенча, ел башыннан ведомствода кар өю һәм кар чыгаруны оештырмау мәсьәләләре буенча 100 мөрәҗәгать кабул ителгән. Тиеш булмаган урыннарга пычрак кар чыгаруның 34 очрагы билгеле булган. 13 кешегә (физик һәм юридик затларга) административ материаллар төзелгән.

– Без М14 микрорайонында, Андрей Адо урамында яшибез. Йорт каршыбызда матур итеп агачлар утыртылган, посадка. Бер ай чамасы элек бездән ерак булмаган урынга пычрак кар китереп түгә башладылар, – дип мөрәҗәгать итте редакциягә Юлия Насыйбуллина. – Ул вакытта юлның каршы ягына бушаталар иде, зур-зур пычрак кар өемнәре барлыкка килә башлагач, йортта яшәүчеләр ризасызлык белдереп, Экология министрлыгына хат язды. Министрлыктан закон бозу очрагы расланган җавап хаты килгәч, машиналар карны безнең йортларга якынрак посадка артына аудара башлады. Монда да пычрак кар өемнәре барлыкка килде. Тагын хат яздык, бу юлы җавап кайтаручы булмады. Тик соңыннан без аның пычрак карны вакытлыча җыя торган махсус урын икәнлеген белдек.

Юлия Насыйбуллина фикеренчә, бу, беренче чиратта, табигатькә бик зур зыян сала.

– Матур гына үсеп утырган агачлыкка химикат ташыйлар. Агачларны сындырып бетерделәр. Нәтиҗәсен яз, җәй көннәрендә күрербез инде.

Икенчедән, көне-төне кар бушаткан арба тавышы колакны яра. Көндез алай ук сизелми, чөнки машиналар берәмләп кенә йөри. Ә төнлә дүртәр-бишәр машина килә. Алар бер дә туктап тормыйлар. Нәрсә эшләргә дә белмибез, – ди ул.

Экология министрлыгы мәгълүматлары буенча, ярамаган урынга кар түгү расланган очракта, гражданнарга 1–2 мең, вазыйфаи затларга – 10–30 мең, юридик зат булмаган эшмәкәрләргә 30–50 мең сум штраф яки 90 тәүлеккә кадәр эшчәнлеген туктатып тору, юридик затларга 100–250 мең сум күләмендә штраф яки шулай ук 90 тәүлеккә кадәр эшчәнлеген туктатып тору каралган.

Пычрак кар чыгару очраклары турында республиканың экология җәмәгать кабул итү бүлегенә (843) 267-68-67 телефоны буенча мөрәҗәгать итәргә кирәк. Шулай ук eco.signal@tatar.ru адресы белән хат та юлларга була. Болардан тыш, +79872169779 буенча «Ватсап» һәм «Телеграм» аша да хәбәр юллау мөмкинлеге бар.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Лилия МИНДУБАЕВА,
Азнакай районы хакимиятенең матбугат үзәге хезмәткәре:

– Шәһәр янында пычрак кар өчен махсус урын билгеләнгән. Әлегә урамнардагы кар шунда чыгарыла. Ләкин эретү корылмасын сатып алу яки төзү планда бар. Быел, башка еллардан аермалы буларак, халыктан мөрәҗәгатьләр күп булды. Без аларны вакытында хәл итәргә тырышабыз. Авылларда проблема юк. Һәр авыл Советы юлларны карап, чистарттырып тора.

Зөһрә ГАРИФУЛЛИНА,
Биектау районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы:

– Карны, мөмкинлек булса, башка җиргә чыгарыр идек, чөнки быел ул бик күп. Тик әлегә урамнарны булдыра алганча киңәйтәбез генә. Барысы да шәп дип әйтеп булмый, ләкин биш авылда да юлларны машина узарлык итеп ачабыз. Авыл советы акчасы гына җитми, билгеле. Әле ярый «Әсән» хуҗалыгы ярдәмгә килә. Кучергән акча әллә кайчан бетсә дә, булышудан туктамыйлар. Барлык авылда да шул ук хәл. Район үзәгендә дә эретү пункты юк. Карны ике урында туплыйлар. Ярдәмгә хуҗалыклардан да машиналар килә. Чөнки кар күп, чыгарып бетерә торган түгел.

25 февральдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Чулпан Гарифуллина** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Чәчәк үстерергә ярыймы?

Тотылган автомобиль шиннарыннан ясалган савытларга утыртып, былтыр урам буенда чәчәк үстергән идек. Шул гамәлебез кайбер күршеләргә ошап бетмәде. Иске шиннар кояш җылысында зарарлы матдәләр чыгарып утыра, шикаять язабыз, дип тәңкәгә тиделәр. Быел нишләргә икән дип уйга калдык инде. Безне моның өчен җаваплылыкка тартырга мөмкиннәрме?

Гафур ГАЙНЕТДИНОВ.
Яшел Үзән, Осиново бистәсе

Виктория Железнова,
Россия бакчачылары берлеге юристы:
– Юк, сезнең очракта бернинди җаваплылык та каралмаган. Әгәр автошиннарны санкцияләнмәгән килеш утильләштерсәләр яки үз белдекләре белән теләсә кайда өеп куйсалар (аның өчен махсус урыннар билгеләнергә тиеш), штраф салынырга тиеш. Әгәр дә инде хуҗалыкта үз ихтыяҗларыгыз өчен куллансагыз, сезне җаваплылыкка тарта алмыйлар, чөнки автошиннарны икенче тапкыр куллану закон буенча тыелмаган.

Боздан ничек котылырга?

Юеш кар яки яңгыр явып үтсә, бакчадагы агачларга боз ката, ботаклар сына. Бозны куптара башласаң, кайрысы да кубып чыга. Мондый очракларда нишләргә икән?

Нәфисә ҺАДИЕВА. Баулы

Лилия Вәлиева, һәвәскәр бакчачы:
– Мондый күренеш бик матур кебек тоелса да, агачлар өчен бик куркыныч. Бозлы яңгыр җир өстендә температура – минус, ә атмосфераның югары катлауларында плюс булганда ява, ягъни һавадагы су тамчылары берәр өлеккә төшү белән салкында катып китә. Бозның калынлыгы 10–15 миллиметрга җитәргә мөмкин. Бу – үсемлекләр өчен бик зур авырлык. Шуңа күрә аларга ярдәм кирәк. Ботаклар сынмасын өчен терәү куегыз, бик озыннарын киссәгез дә ярый. Дөрес, кыш көне ботак кисү бик үк яхшы түгел. Әмма икенең берсен сайларга туры килә инде. Бозны каерып алырга тырышмагыз, чөнки кайрыга, чыннан да, бик зур зыян килергә мөмкин.

Йортны ничек теркәргә?

Йорт-җиргә кагылышлы берничә соравым бар иде. Шәхси йортны теркәү өчен эшне нидән башларга, нинди документлар кирәк икән? Җир участогын бүлеп алмыйча гына үз өлешемне башка кешегә сата яки бүләк итә аламмы? Кирәксенмәгән очракта мин җир участогыннан ничек баш тарта алам?

Галия САТТАРОВА. Казан

Галина Галиуллина,
Росреестрның Татарстандагы идарәсенең матбугат үзәге җитәкчесе:
– Әгәр йортыгыз салынган җир участогы шәхси йорт төзелеше, хуҗалык алып бару, бакча үстерү өчен билгеләнгән икән, аны гадиләштерелгән тәртиптә, ягъни дача амнистиясе буенча теркәргә була. Моның өчен кадастр инженерына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ул техник план әзерли. Аннан соң 350 сум күләмендә дәүләт пошлинасы түләп, милек хокукын теркәү өчен теләсә кайсы күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәргә була. Шулай ук белдерү тәртибе белән эшләргә дә була. Башта төзелешнең башлануы һәм тәмамлануы турында башкарма хакимият органына хәбәр итәсең. Төзелеш объектының яраклылыгы турында хәбәр алгач, техник план һәм дәүләт пошлинасы түләү турындагы документны алып, күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәсең.

101-ФЗ номерлы законның 12 маддәсендә әйтелгәнчә, җирне бүлеп алмыйча гына үз өлешеңне шул ук җирдә өлеше булган кешегә яки, өлештә булып, шул җирдән файдаланучы крестьян-фермер хуҗалыгына сатарга яки бүләк итәргә мөмкин. Әгәр сатып алучы яки бүләк кабул итүче өлештә тормаса, аларга җирне бүлеп алганнан соң гына сатарга яки бүләк итәргә була.

Җиргә милек хокукын туктату буенча дәүләт теркәве узар өчен милек хуҗасына гариза язу да җитә. Җиргә хокук теркәлгән булса, өстәмә документлар кирәкми.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Пенсияне ничек арттырырга?

Мин пенсиягә чыксам да, балаларга булышыйм дип, эшләп йөргән булам әле. Тик эшләмәүче пенсионерларның ел саен пенсиясе арткач, күңел төшә. Рәхәтлектән йөрмисең бит инде. Эш урынымнан китсәм, яңадан урнаша алмам дип куркам. Нишләргә икән?

Гөлфизә СӘЙРАНОВА. Чаллы

Андрей Гиринский,
икътисад белгече, доцент:
– Чыннан да, пенсия эшләмәүче пенсионерларга гына арта. Шулай булгач, бер генә юл кала: эштән китәргә, пенсияне арттырырга һәм яңадан эшкә урнашырга. Әмма сез дөрес әйтәсез, пенсия яшендә эшкә урнашу кыен булачак. Яңадан эшкә урнаша алсагыз, индексацияләү туктатылмый, пенсия күләме кимеми.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

Кайтаваз

Нәкъ безнеңчә икән

Газетада космоска очарга җыенучы Фәрит Әюпов турында бик кызыклы язма укыдык. Бер яктан карaганда, галәмгә менүче кеше әллә нинди шөгыльләр белән яшидер кебек. Баксаң, ул да бик гади тормышта яши, нәкъ безнең кебек, хәрәкәттә – бәрәкәт, дигән гыйбарәгә тугры кала икән. Менә үзем дә, яшем шактый олыгайса да, җир кар белән каплануга, декабрьнең унбишеннән чаңгыга бастым – һәр көнне сәгатьтән артык очынып шуып, карт сөякләрне язып, рәхәтләнеп кайтам. Фәрит тәкъдим иткәнчә, җәмәгатем Розалия белән кимендә 10 мең адым җәяү йөрергә тырышабыз. Космоска очарга җыенучының ашау-туклануы да нәкъ безнеңчә икән. Авылда яшәгәч, без бит әле үзебез җитештергән-үстергән биологик чиста ризык кына ашыйбыз дияргә була. Ит – үзебез җыеп ашаткан кычыткан, тузганак кебек үләннәрдән, бодай ярмасы, вак кабырчык, чуерташлардан тупланган бройлер тавыкларыныкы. Булачак космонавтның иң яраткан салаты да гади генә кәбестә икән. Анысы да күп бездә. Базыбызда бик әйбәт саклана.

Форсаттан файдаланып, мин дә бик тәмле рецепт тәкъдим итим әле. 3 кг кәбестә, 3 зур кишер, 3–4 тырнак сарымсакны вак кына турыйбыз, 2 чынаяк шикәр комы, 1 чынаяк көнбагыш мае, 1 чынаяк серкә һәм 3 аш кашыгы тозны 1,5 литр суга салып кайнаткач, кәбестәгә салабыз да, 2 сәгатьтән соң банкага тутырып, суыткычка урнаштырабыз.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы Сәпәй авылы

Фикер

Татар теле – нәфис тел

Бик күпләр балаларын татар мәктәпләренә, гимназияләренә бирергә ашыкмыйлар. «школа»ны сайлыйлар. Анда бала русча аралашып, укып, татарчаны чит күрә дә күрә инде. Шул мохиттә тәрбия ала. Татарның тамыры шунда корый башлыйдыр дип уйлыйм мин. Бөек Тукай туган телебезне асылташка тиңләгән. Татар теле – чыннан да, иң матур, нәфис телләрнең берсе бит ул. Балачакта үзләштерсәң, тел һич тә онытылмас, гомер буе озата барыр ие.

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА. Апас районы

Тормыш үзе тәгәрәп ята

Газетаны үземне белгәннән бирле укыйм, алдырам. 2011 елда улым Айзатның «Яшьлегем хыялы» дигән мәкаләсе дә басылган иде. Ул – хәрби очучы, капитан. Хабаровск краенда хезмәт итә. 2020 елда 80 яшьлек юбилеем уңаеннан бер язма басылды. Бик күңелле булды. Тик газеталарны вакытында бирмичә генә йөдәтәләр. Бер номерны ике тапкыр китерсәләр, кайберсен бөтенләй күрми дә калабыз. Хат ташучыны да гаепләп булмый. Озын-озын урамнар буйлап берүзе чаба.

Газета килү – минем өчен бәйрәм. Башыннан ахырына кадәр укып чыгам. Һәркайсында тормыш үзе тәгәрәп ята бит. Әле менә Габделбәр Ризвановның сугыш ятимнәре турындагы язмасын укыдым. Әтием миңа бер яшь булганда сугышка киткән. Энем 1942 елның 12 маенда туган. Әтием икенче улы туасын белми дә калгандыр инде. Аның ике генә хаты килгән. Әнием әтине гомер буена көтте. Соңгы хатында, сугышка керәбез, дошманнар сезнең янга килеп җитә алмаслар, дигән. Әтинең кайда сугышканын да, кайда һәлак булганын да белмим. Михаил Черепанов та әйтә алмады. Соңгы хаты да сакланмаган. Берни эшләп булмый. Калганнарыбыз исән-сау булыйк.

Салихҗан НАСЫЙБУЛЛИН

21 февраль | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30,21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00, 02.50 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
10.00, 23.30 «КОРОТКОЕ ДЫХАНИЕ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 19.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Реальная экономика» 12+
00.15 «Черное озеро» 16+
00.40 «Соотечественники» 12+
01.05 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
07.15, 19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 0+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
17.00 «Время покажет» с Артемом Шейниным 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. Игорь Костолевский и Игорь Гордин. «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК» (S) 16+
23.20 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.00 «Познер» 16+
01.05 «Время покажет» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55, 02.20 «ВТОРОЕ ДЫХАНИЕ» 16+
17.15 «Андрей Малахов» 16+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «КОГДА ЗАКОНЧИТСЯ ФЕВРАЛЬ» 12+
23.20 «Вечер» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.20, 14.50 Новости
06.05, 16.30, 18.45, 23.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.25 Специальный репортаж 12+
09.30 Смешанные единоборства. Eagle FC. Трансляция из Москвы 16+
10.25 Бокс. Bare Knuckle FC. Трансляция из США 16+
11.20 «Есть тема!» Прямой эфир
12.45 «ОФИЦЕРЫ» 16+
14.55 XXIV Зимние Олимпийские игры. НАШИ победы 0+
18.40 Новости
20.55 Футбол. Чемпионат Италии. «Кальяри» – «Наполи». Прямая трансляция
23.00 Тотальный футбол 12+
00.15 «РОЖДЕННЫЙ ЗАЩИЩАТЬ» 16+
02.05 «Конор Макгрегор. Печально известный». Док. фильм 16+
03.50 Новости 0+
03.55 «Наши иностранцы» 12+
04.25 «Всё о главном» 12+
04.55 Танцевальный спорт. Кубок мира по латиноамериканским танцам среди профессионалов. Трансляция из Москвы 0+

НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00 Сегодня
08.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
10.00 Сегодня
10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.00 Сегодня
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.00 Сегодня
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.00 Сегодня
20.00 «ЗОЛОТО» (S) 16+
23.15 Сегодня
23.35 «ПЁС» (S) 16+
03.30 «СХВАТКА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «ТАКАЯ, КАК ВСЕ» 16+
06.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Чёртово перо» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.10 «Верну любимого» 16+
14.45 «ВТОРАЯ ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ» 16+
19.00 «ПРЯНЫЙ ВКУС ЛЮБВИ» 16+
23.15 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 2» 16+
01.15 «Понять. Простить» 16+
02.15 «Порча» 16+
02.40 «Знахарка» 16+
03.05 «Верну любимого» 16+
03.30 «Тест на отцовство» 16+
05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «МУР ЕСТЬ МУР!-3» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 18.30 «Специальный репортаж» 16+
09.40 «БЕРЕГИТЕ МУЖЧИН!» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
14.05 «ВИКИНГ» 16+
18.50 «Непобедимая и легендарная». «История Советской армии» 16+
19.40 «Скрытые угрозы» 16+
20.25 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Неизвестные страницы Войны Судного дня. Свидетельства очевидца» 12+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.40 «МАРШ-БРОСОК. ОХОТА НА «ОХОТНИКА» 16+
03.15 «Из всех орудий». Док. сериал. 16+
03.55 «ВИКИНГ» 16+

22 февраль | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00, 02.50 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
10.00, 23.00 «КОРОТКОЕ ДЫХАНИЕ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Чёрное озеро» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». «Что так сердце растревожено...» – Ринат Ибрагимов 12+
00.40 «Черное озеро». Лихие парни из Уфы 16+
01.05 «Реквизиты былой суеты» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
07.15, 19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10 «Язмыш». Әзһәр Шакиров 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 0+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
17.00 «Время покажет» с Артемом Шейниным 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК» (S) 16+
22.25 Премьера. Юбилейный концерт Вячеслава Бутусова (S) 12+
00.25 «Познер» 16+
01.35 «Наедине со всеми» 16+
02.20 «Модный приговор» 0+
03.10 «Давай поженимся!» 16+
03.50 «Мужское/Женское» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55, 03.00 «ВТОРОЕ ДЫХАНИЕ» 16+
17.15 «Андрей Малахов» 16+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. «КОГДА ЗАКОНЧИТСЯ ФЕВРАЛЬ» 12+
23.20 «Вечер» 12+
02.20 «Идущие в огонь» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.20, 14.50, 18.25, 22.00 Новости
06.05, 18.30, 22.05, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.25 Спецрепортаж 12+
09.30 Смешанные единоборства. UFC. Трансляция из США 16+
10.25 Профессиональный бокс. Трансляция из Екатеринбурга 16+
11.20 «Есть тема!» Прямой эфир
12.45 «ОФИЦЕРЫ» 16+
14.55 Лыжные гонки. Чемпионат мира среди юниоров. Масс-старт. Женщины. Прямая трансляция из Норвегии
15.45 «МатчБол»
16.25 Матч! Парад 0+
16.55 Лыжные гонки. Чемпионат мира среди юниоров. Масс-старт. Мужчины. Прямая трансляция из Норвегии
19.10 Смешанные единоборства. UFC. Трансляция из США 16+
20.00 Профессиональный бокс. Прямая трансляция из Москвы
22.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. «Челси» (Англия) – «Лилль» (Франция). Прямая трансляция
01.50 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. «Вильярреал» (Испания) – «Ювентус» (Италия) 0+
03.50 Новости 0+

НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00 Сегодня
08.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
10.00 Сегодня
10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.00 Сегодня
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.00 Сегодня
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.00 Сегодня
20.00 Премьера. «ЗОЛОТО» (S) 16+
23.15 Сегодня
23.35 «ПЁС» (S) 16+
03.25 Их нравы 0+
03.40 «СХВАТКА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.50 «Давай разведёмся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.05 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Куколка» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «БОЛЬШЕ, ЧЕМ ВРАЧ» 16+
19.00 «ТЕНИ СТАРОГО ШКАФА» 16+
23.15 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 2» 16+
01.10 «Понять. Простить» 16+
02.10 «Порча» 16+
02.35 «Знахарка» 16+
03.00 «Верну любимого» 16+
03.25 «Тест на отцовство» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ВИКИНГ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20 «МАКСИМ ПЕРЕПЕЛИЦА» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
14.05 «ВИКИНГ-2» 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Непобедимая и легендарная». «История Советской армии» 16+
19.40 «Легенды кино». «Одиннадцать молчаливых мужчин» 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «Маршал Победы Говоров» 12+
00.55 «БЕЗ ПРАВА НА ПРОВАЛ» 12+
02.10 «Полководцы России. От Древней Руси до XX века». Док. сериал. Барклай-де-Толли и Багратион 12+
02.55 «Полководцы России. От Древней Руси до XX века». Док. сериал. Мономах 12+
03.35 «Полководцы России. От Древней Руси до XX века». Док. сериал. Ушаков 12+
04.15 «Полководцы России. От Древней Руси до XX века» 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 21–27 ФЕВРАЛЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Берара кесәгез такыраеп калган кебек булыр. Әмма хафаланасы түгел. Бик тиздән матди якны яхшыртырдай искитмәле мөмкинлекләр ачылачак. Моңарчы уегызга да кереп карамаган мөмкинлекләр!

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Очраклы гына килеп чыккан бер хәл тормышыгызга ямь өстәп җибәрер. Тик менә кемнәрнеңдер сезнең хакта ямьсезрәк имеш-мимешләр тарата башлавы гына... Күрмәмешкә салышмагыз, аларны чыгарган кешене бик тиз генә тирәгездән алып ташлагыз.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Бу чорда сезгә күп ишекләр ачылачак. Каушап кына калмаска! Эштә үзегезне күрсәтүдән оялмагыз, ә өйдә бердәнберегезгә юл куегыз. Атна ахырында, сәеррәк яңалык ишетеп, уйга калырсыз.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Сак булыгыз: таркаулык, игътибарсызлык уңайсыз хәлгә куймагае. Өйдә генә түгел, кеше арасында да! Керем китерердәй теләсә нинди тәкъдимгә ризалашыгыз – үкенмәячәксез. Тормышыгызда бер мәсьәләгә ачыклык керткән хәбәр ишетерсез.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Күңелегез үзгәрешләр көтәме? Озакламый бер-бер артлы килеп чыга башлаячак алар. Берсе-берсенә бәйләнгән, һәммәсе дә – бары тик уңай! Бәхетле кеше шул сез!

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Атна башында, кесәгезне ертып дигәндәй, керем килеп керер. Аптырап калмагыз, тырышмаган кешегә эләкми ул. Ләкин сәламәтлеккә игътибарлырак булу кирәк. Суык тидерүдән дә курка торган вакыт бит.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Яшьләр мәхәббәт «өчпочмагы»на килеп эләгергә мөмкин. Шундук барысына да ачыклык кертергә тырышыгыз: сезгә мондый катлаулы мөнәсәбәтләрнең кирәге юк. Ә өлкәнрәкләр атна буе үзләрен бик бәхетле сизәр.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Көч-куәтегезнең ташып торуы шәп кенә уңышларга китерер. Әлбәттә инде, акчасы да булыр. Тирәгездәге кайберәүләр хәтта көнләшә башлар. Гомумән, тормышыгызда кардай ап-ак полоса башланып китәр.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Ялкаулык төп дошманыгызга әйләнмәгәе. Шуның аркасында эшегезне вакытында төгәлли алмавыгыз, якыннарыгызны авыр хәлдә калдыруыгыз бар. Үзегезне кулга алып, бөтен тырышлыкны бер йодрыкка төйнәгез дә – алга!

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Акча мәсьәләсе баш калкытыр, һәм сез аны ялгыз гына хәл итә алмассыз бугай. Әмма әйбәт яңалык та бар: атнаның икенче яртысында финанс хәлегез яхшыра башлар. Ял көннәрендә ишетелгән бер яңалык зур планнар коруга этәрер.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Хезмәттәшләрегез һәм җитәкчегезне шаккатыру мөмкинлеге чыгар. Кайбер кемсәләрнең борыннарына чиертү булачак бу! Атна ахырында күңелегезне җилкетеп җибәрердәй хәлләр булып алыр.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Килеп туган хәлләр шәп кенә планнарыгызны тормышка ашыру мөмкинлеге бирер. Акча мәсьәләсе уңай хәл ителеп, бөтен борчу-дулкынлануларыгыз узганда калыр. Җитәкчегезнең эшегезне тиешенчә бәяләве үзегезгә көч-куәт өстәп җибәрер.

СТЕНА СӘГАТЬЛӘРЕ ТӨЗӘТӘМ.
Тел.: 89274383839
Айдар
Парин ур., 4а, 121

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

БАЛАНЫ ДА АЯКТАН ЕГА

pixabay.com

Соңгы арада Россиядә коронавирус йоктырган балалар саны ике тапкыр арткан. Хәзер алар барлык авыручыларның 20 процентын тәшкил итә. Баштарак коронавирусны җиңелчә генә уздыра дип саналган балалар да хәзер чирне авырдан кичерә башлаган. Республикада вазгыять ничегрәк?

Татарстанның баш педиатры Светлана СЕНЕК балаларның коронавирусны ничек кичерүләре турында сөйләде.

:: Светлана Александровна, хәзер балалар коронавирусны авыррак кичерә, диюләре дөресме?
– Хәзерге вакытта Татарстанда 5170 бала коронавирус йоктырган. Шуларның 4847се өй шартларында дәвалана. Коронавирус башланганнан соң ике ел дәвамында балалар арасында бу кадәр авыручылар саны теркәлгәне юк иде әле. Чирнең иң югары ноктасына җиттек. Коронавирус белән авыручы сабыйлар арасында чирне җиңелчә уздыручылары да, авыр формада үткәрүчеләре дә бар. Бәхеткә, ясалма сулыш аппаратына тоташтырылган балалар юк. Ковид-госпитальдә балалар өчен 385 ятак урын исәпләнә. Биредә, нигездә, бер яше тулмаган балалар ята. ДЦП диагнозлы, шикәр чирле, артык авырлыктан интеккән балалар да, коронавирус йоктырган очракта, биредә дәвалана.

:: Коронавирус йоктырган балада нинди билгеләр күзәтелә?
– Коронавирус йоктырган баланың, иң беренче чиратта, температурасы күтәрелә. Ул берничә көн дәвамында югары килеш саклана. Бала сүлпән, хәлсезгә әверелә. Коронавирус борынга томау төшү, тамак авырту, косу, күңел болгану, эч авырту кебек билгеләрдән дә башланырга мөмкин. Әлеге авыру өске сулыш юлларына һәм бронхларга зыян сала. Моңарчы булмаган бронхиолит очраклары да бар. Һәр өченче балада – диарея.

:: Ничә яшьлек балалар чирне авырдан уздыра?
– Яшүсмерләр коронавирусны авырдан уздыра. Бу аңлашыла да. Үсмерлек чоры организмында гормональ үзгәрешләр барган вакыт. Шуңа күрә алар коронавирусны да авырдан кичерә. Аларда бу чирнең ни рәвешле узачагын да алдан фаразлап булмый. Шуңа күрә яшүсмерләргә коронавируска каршы прививка ясатырга киңәш ителә дә инде. Вакцина ясаткан бала, авырган очракта да, чирне җиңелрәк уздырачак.

:: Ковид белән авырып терелгән бала тернәкләнү чорын ничек уздыра?
– Коронавирус белән авырып терелгән балада, бигрәк тә яшүсмерләрдә бер ай дәвамында югары температура сакланырга мөмкин. Моннан тыш алар даими рәвештә баш авыртудан да зарланырга мөмкин. Коронавирус белән авырып терелгән бала аз гына физик һәм акыл хезмәтеннән соң да хәлсезләнә, тиз арый. Кечерәк балаларда исә ковидтан соңгы чор, гадәттә, бернинди билгеләрсез генә уза. Ковид белән авырып терелгән балага ике атна өйдә торып тернәкләнергә кирәк. Аннан соң мәктәпкә, балалар бакчасына барса була.

:: Баланың коронавирус йоктыруын кисәтү өчен нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк? Бу уңайдан ата-аналарга нинди киңәшләр бирер идегез?
– Баланың көнлек режимы саклануны кайгыртыгыз. Йокысы туйганчы йокласын, саф һавада йөрсен. Чир котырган чорда кеше күп йөри торган урыннарда да сирәк булу хәерле.

Иммунитетны ничек ныгытырга?

➤Гөлҗимеш чәе эчәрергә кирәк. Анда С витамины күп. Әмма гөлҗимешне чамасын белеп кенә кулланырга кирәк. Ник дигәндә, ул организмнан калийны чыгара. Шуңа күрә гөлҗимеш чәе эчкәннән соң күрәгә, йөзем яки банан ашатырга кирәк.
➤Шикәр урынына бал куллану хәерлерәк. Дөрес, бу киңәш баланың балга аллергиясе булмаган очракта гына ярдәм итәчәк.
➤Атнага ике тапкыр кызыл балык ашагасыз файдага булыр. Аның составындагы омега-3 майлы кислотасы иммунитетны, кан тамырларын, нерв тукымасын ныгыта.
➤Атнага ике тапкыр 20–30 грамм чикләвек ашауның да иммунитет өчен файдасы зур.

Файдалы төнәтмә

➔Ике зур лимон алып, согын сыгарга. Шул ук күләмдә бал кушып, сүрән утта җылытып алырга. Катнашманы берәр атна дәвамында иртәләрен эчегез.
➔1 стакан бал, 50 г имбир тамыры, 1 лимон алырга. Лимонны кабыгы белән бергә угычтан уарга, төшләрен ташларга. Имбирне әрчеп, вак итеп турарга. Банкага салып, өстенә бал агызып, әйбәтләп болгатырга. Ике ай караңгы урында торганнан соң көнгә 3 тапкыр берәр аш кашыгы эчәргә киңәш ителә.
➔Сарымсакны угычтан уып, бергә-бер исәбендә бал белән болгатырга. Ашар алдыннан көненә өч тапкыр бер бал кашыгы кабып куярга.

Коронавирустан вакцина турында 5 сорауга җавап



Хәзерге вакытта Татарстанда 1,3 мең үсмергә коронавируска каршы вакцина ясалган. Биредә 12–17 яшьлек яшүсмерләр турында сүз бара. Ата-ана балаларга вакцина ясау турында нилэр белеп торырга тиеш?

✸**Ничек әзерләнергә?** Вакцина ясатыр алдыннан участок педиатры баланы тикшерергә тиеш. Ул аның тән температурасын, кан басымын үлчи, хроник чирләре, аллергиясе бармы-юкмы икәнлекне ачыклый. Соңгысы күзәтелгән очракта, андый балаларга вакцина ясатырга 3–4 көн кала аллергиягә каршы дарулар эчәргә, махсус диета сакларга туры килүе бар.
✸**Ясаткач, ни эшләргә?** Вакцинациядән соң беренче ике көндә баланың тән температурасы күтәрелергә, калтыратырга, тән, буыннар сызларга, укол урыны авыртырга яки кычытырга мөмкин. Тән температурасы күтәрелгәндә аңа температураны төшерә торган дару эчерергә кирәк.
✸**Мәктәпкә барасымы?** Вакцина ясатканнан соң баланың көндәлек режимы төгәл сакланырга тиеш. Бу чорда авыр физик эш башкару, күнегүләр ясау киңәш ителми. Бала вакцина ясатканнан соң өч көн мәктәпкә бармаса хәерле.
✸**Кемнәргә ясатырга ярамый?** Коронавирус белән авырып ятучы, хроник чирләре баш калкыткан балаларга вакцина ясатырга ярамый. Аутоиммун авырулардан, яман шештән интегүчеләргә дә коронавируска каршы вакцина ясату тыела.
✸**Борынга салынамы?** Баштарак балалар өчен чыгарылган вакцина борынга салыначак дигән хәбәр таралган иде. Әмма ул дөреслеккә туры килми. Балалар өчен чыгарылган «Спутник М» вакцинасы кулга ясала.

Кирәге чыгар

Балалар өчен нинди спорт төрләре файдалы?

ЙӨЗҮ
Балаларны теләсә кайсы яшьтә йөзәргә өйрәтергә мөмкин, йөзү бөтен мускулларны тигез үстерә, ныклы иммунитет булдыра. Әлеге спорт төре баланың тән авырлыгын нормада тота, үпкәләрне һәм умыртка баганасын ныгыта, чыдамлылык булдыра.

БИЮ ҺӘМ ГИМНАСТИКА
Бию, аэробика һәм нәфис гимнастика хәрәкәт координациясен яхшырта, гәүдәнең дөрес формалашуы белән беррәттән, матур итеп йөрү күнекмәләрен дә булдыра. Бу спорт төрләре балага ритмны тоярга өйрәтә, гәүдәсен сыгылмалы итә.

УШУ, АЙКИДО
Көнчыгыш көрәш төрләре саналган ушу белән айкидо баланың гәүдә үсешенә яхшы йогынты ясый, төгәл координация булдыра, үз-үзен сакларга, кыю һәм чыдам булырга, һәр адымын уйлап башкарырга өйрәтә. Әлеге төр көрәшләр белән шөгыльләнгәндә төрле җәрәхәтләр алу куркынычы азрак.

ФУТБОЛ, БАСКЕТБОЛ, ВОЛЕЙБОЛ
Футбол балаларда максатчанлык, чыдамлык кебек сыйфатларны булдыра, хәрәкәтләр координациясен яхшырта. Футбол, баскетбол, волейбол бөтен мускулларны ныгытуда да ярдәм итә. Баскетболда бала тупны ике кулы белән дә йөртергә, футболда исә тупны кабул итәргә һәм ике аягы белән дә пас бирергә өйрәнә. Шул рәвешле аның координациясе яхшыра һәм гәүдәсе төз була. Моңа кадәр умыртка баганасында булган кимчелекләр дә узарга мөмкин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Бу – кызык!

Ир-атлар бәйрәмен бездә генә түгел, бөтен дөньяда бәйрәм итәләр. Тик төрле илләрдә – төрле вакытта. Әйтик, **Германиядә** 17 майда билгеләп үтелә. Хатын-кызлар бүләк әзерләми. Гомумән бу көнне ирләр, гүзәл затлардан баш тартып, үзләре генә күңел ача. Шарты шундый! **Америка, Төркия** ирләре июльнең өченче якшәмбесендә хөрмәтләнә. Бу көнне әтиләргә аеруча зур игътибар күрсәтелә. Аларга алсу розалар бүләк ителә. **Италиядә** ирләр бәйрәме 19 мартта билгеләп үтелә. Гүзәл затлар үзләренең бердәнберләренә, холкы, тормыш рәвеше һәм хатта йөз-кыяфәтеннән чыгып, шәраб бүләк итә. Ә менә Кытайда бу бәйрәм 11 ноябрьгә туры килә. Ләкин анда... буйдаклар гына кадер-хөрмәткә күмелә. 11.11 – гел бердән тора һәм бу сан ялгыз ирләрне гәүдәләндерә, имеш. Бу бәйрәмне аеруча яшьләр көтеп ала, чөнки буйдаклар күңелендә бердәнберенне җиңел генә табарга мөмкин дип санала.

Бакчачы почмагы

Гади һәм купшы петуния

Петуния чәчәргә вакыт. Ләкин алар күп төрле. Чүлмәккә, клумба һәм газоннарга күчереп утырту өчен петуниянең ниндирәк сортын чәчү әйбәтрәк?

Чәчәкнең ампель, каскадсыман һәм куаксыман сортлары була.

Ампель сортының һәр ботагы 1әр метр озынлыкта үрмәләп үсә. Аны гадәттә чүлмәккә күчереп утыртып, элеп кую өчен чәчәләр.

Каскадсыман чәчәкләр вазоннарда, шулай ук чүлмәкләрдә бик матур булып үсеп утыра. Аларның сабаклары 50–70 сантиметрга җитә.

Куаксыман петунияләр гадәттә клумбага, сукмак кырыйларына күчереп утырту өчен чәчелә. Як-якка таралып үсми торган җыйнак чәчәкләр бу. Шулай ук озын тар савытларга утыртып, урам якка өй яки балкон, терраса тәрәзәләре астына урнаштырып үстерү өчен дә кулай сорт санала.

Бу сортлар берничә төргә бүленә. Әйтик, эре яки вак, гади яки купшы чәчәкләренә, кәрлә яки гигант төрләргә. Монысын орлыкны сатып алганда, кабыннан укып белергә мөмкин.

Кактуска уянырга вакыт

Чәнечкеле гөлләрне февраль ахырында «йоклы»сыннан уянырга ярдәм итәргә кирәк. Моның өчен аларны, беренчедән, ике атна дәвамында ике-өч көнгә бер тапкыр 1–2 сәгатькә кояшлы урынга куеп торабыз. Шулай да кояш күзенә түгел, бераз күләгә ясап. Гөл кояшка акрынлап кына ияләшергә тиеш.

Икенчедән, чүлмәкләре кысан була башлаган яшь кактусларны – зуррагына, шулай ук кактус «бәби»ләрен күчереп утыртабыз. Шунысы бар: күчереп утыртырга 2–3 атна кала һәм аннан соң шул чама вакыт эчендә кактуска су сибәргә ярамый.

Февраль ахыры – март башында утыртылган яки күчереп утыртылган кактуслар бик тиз үсеп китә.

СЕЗНЕҢ ХӨРМӘТКӘ, ИРЛӘР!

Ватанны саклаучылар көне якынлашып килә. Туташ-ханымнарга бүләк кайгыртырга да вакыт, димәк. Оекбаш, хушбуй, дезодорант, кырыну өчен күбек ише әйберләр биреп «куандырганчы», бүләкне үз кулларыбыз белән эшләү көчле затларыбызның күңелләренә күбрәк хуш килер.

Фудфлористика – ашарга яраклы букетларның модада булуын исәпкә алып, үз эшенең остасы Гөлназ ШАҺИӘХМӘТОВАдан ир-атларга шундый бүләк әзерләү серләрен белештек.

Кирәк булачак: ике төрле ярымысланган колбаса, ике төрле сыр (берсе – каты, тишекле (әйтик, «Маасдам», икенчесе – ысланган, үргән), дүрт аэрбайҗан гранаты (вак), 1 «Бородинский» икмәге, 1–2 кисәк күркә итеннән ветчина, бамбук таякчыклары, бизәү өчен – яшеллек (яшел суган, петрушка ботаклары яки салат яфраклары), букетны төрү өчен матур кәгазь.

Башта бәйләм өчен кирәкле ингредиентларны әзерлибез. Колбасаны кыеклап кисеп, таякчыкларга тыгабыз. Тишекле каты сырны – өчпочмаклап, үргән сырны – икегә бүлеп, икмәкне – яртылаш бүлеп, ветчинаны – дүртпочмаклап бүлеп, гранатның өстен кисеп алып, таякчыкларга урнаштырабыз. Яшеллек белән бизәп, таякчыкларны скотч ярдәмендә берләштерәбез. Килеп чыккан бәйләмне матур итеп кәгазьгә төрәбез.

Ирләр букетына шулай ук багет, черри помидорлары, сары яки кызыл төстәге ваграк татлы борыч, матур шешәле су, кипкән җимешләр дә өстәргә мөмкин. Кәгазь төргәкне үргән кәрҗингә яки агач тартмага алыштырсак, тагын да матуррак килеп чыгачак.

Белеп тор!

КАР КӨРӘККӘ ЯБЫШСА

Җепшек кар пластик көрәккә ябышмасын өчен нишләргә? Сере бик гади. Көрәкнең эчке өслеген (коры булырга тиеш) аяк киеме өчен силикон губка белән ышкырга кирәк. Бу эшне җылыда – өйдә башкару шарт. Әлеге киңәшне тотканда, көрәктәге кар җиңел генә шуып төшәчәк.

КАМЫР РИЗЫГЫ КӨЙМӘСЕН

Кайвакыт өстен фольга белән каплап пешерү дә бәлеш-күмәчләрне көеп китүдән саклап кала алмый. Мондый очракта хуҗабикәләргә тоз ярдәм итә. Моның өчен газ миченең иң аскы рәшәткәсенә аерым савытка эре тоз салып куярга кирәк. Болай эшләгәндә, ризык көймәячәк, бик йомшак булачак, тышы кетердәп торачак.

БАШЛЫ СУГАН ХИКМӘТЛӘРЕ

- Суган кабыгын (әйбәтләп юылган булырга тиеш) салып пешергәндә, ит шулпасы алтынсу төскә керәчәк.
- Киемдә үтүк өткән урынны суган суы белән чылатып, берничә сәгатьтән соң юсаң, берниндидә эз калмаячак.
- Пычак йөзендәге, чәнечке-кашыклардагы күгәргән тапларны чи суган бик яхшы чистарта.

АЯК КИЕМЕН САКЛАП КИЯБЕЗ

Кышын юлга һәм тротуарларга сибелгән реагентлар аяк киемен «ашый», анда аксыл таплар калдыра. Моны булдырмас өчен, урамга чыкканчы, итек-ботинкаларны җитен маенда чылатылган мамык белән сөртеп алырга кирәк. Аяк киеме ялтырап китәчәк һәм реагентлар күнгә сеңмәячәк.

Әгәр инде таплар күнгә сеңәргә өлгерсә, аны спирт һәм аш серкәсе катнашмасында (1:1) чылатылган мамык белән чистарту әйбәт.

ТЕШ ПАСТАСЫНЫҢ 4 СЕРЕ

Аны, теш чистартудан тыш, башка максатларда да кулланырга мөмкин булуын беләсезме?

- Теш пастасы термос яки пластик контейнердагы сөрсегән исне юкка чыгара. Моның өчен аңа теш пастасы өстәлгән су салып, төнгә калдырырга кирәк.
- Кухня тәрәзәсе парланмасын өчен, тәрәзәгә теш пастасы сылап, 5–7 минут тотарга һәм шуннан соң юып алырга мөмкин.
- Черки тешләгән урынга, кычытмасын өчен, паста сылап кую әйбәт.
- Тутыкмый торган корычтан эшләнгән савыт-саба, теш пастасы белән ышкып юганда, ялтырап калачак.

Тәмле булсын!

«Фәрештә күз яше» торты

ГӨЛНАЗ ХӘЙРЕТДИНОВА РЕЦЕПТЫ

Камыр өчен: 1 стакан он, 1 чәй кашыгы камыр күперткеч (разрыхлитель), 80 грамм атланмай, 2 аш кашыгы шикәр комы, 1 йомырка сарысы.

Эчлеге өчен: 500 грамм эремчек, ярты стакан шикәр комы, 3 йомырка сарысы, 1 аш кашыгы манный ярмасы, 100 грамм каймак.

Суфле өчен: 4 йомырка агы, 4 аш кашыгы шикәр комы.

Камыр басып, формага яки табага төбен майлап салабыз. Өстенә эчлекне салып, 180 градуска кадәр җылытылган газ миченә куябыз. Ул 30–40 минут тирәсе пешә. Шуннан соң мичтән алып, өстенә суфле (йомырка агына шикәр комы кушып, куерганчы күпертәбез) җәябез дә тагын 10–15 минутка мичкә куеп алабыз. Торт суынганда, өстендә бик матур тамчылар пәйда була.

Әлеге тәмле тортны бәйрәм табынына пешерсәгез, ир-егетләр дә бик канәгать булыр.

Валентина СЕМЕНОВА әзерләде

ДӨЯ СЫМАН ЭЧМӘ, ТАМЧЫСЫН ДА КАДЕРЛӘ

Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) үзенең бер хәдисендә: «Кыямәт көне алдыннан алтын чыгар, су китәр», – ди. Бүген суга кытлык кичереп яшибез дип әйтә алмыйбыз, тик киләчәктә төче суга кытлык туу куркынычы бар, дип кисәтә галимнәр. Димәк, адәм баласына су кебек бәһасез нигъмәтне кадерләп, белеп файдаланыр вакыт җиткәндер инде. Диндә суга караш нинди? Аны нигә исраф итәргә ярамый?

Саба районының Сатыш авылы имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт ГАЛИМҖАНОВ белән суга бәйле сорауларга җавап эзләдек.

:: Су – Җирдәге иң кадерле нигъмәтләребезнең берсе. Ислам динендә су турында ни диелә?

– Бисмилләһир-рахманир-рахим. Аллаһы Тәгалә безгә бик күп нигъмәтләр бирде. Су – шуларның иң олы һәм бәһасе булмаганнарның берсе. Коръән Кәримдә дә су турында күп әйтелә. Аятьләрдә: «Җирләрне вә күкләрне Аллаһы Тәгалә бар итте һәм күктән су төшереп, җирләрне терелтте, сез куллансын өчен төрле җимешләр үстерде», – диелә. Болар барысы да – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте. Кызганыч, билгеле бер хәлләргә юлыкмыйча, без бу нигъмәтләрнең кадерен аңламыйбыз. Әйтик, шул ук ураза тотканда.

Сүз уңаеннан, күктән төшә торган су да бар бит әле. Ул да булса – кар һәм яңгыр. Бу шулкадәр олы бәрәкәт! Еш кына: «һаман кар ява инде, һаман яңгыр туктамый», – дип зарланабыз. Әлбәттә, бу җир эшкәртү, авыл хуҗалыгы белән бәйле булмаган кеше өчен бик зур проблема тоеладыр. Әмма җир кешесе, гомумән, табигать кадерен аңлаган, уйлый-фикерли белгәннәр суның кадерен чамалый. Аллаһы Тәгаләнең биргәненә шөкер: кар күп яуды. Бу бит инде муллык дигән сүз. Яңгыр да, кар да булмаса, корылык көт. Явым-төшемне сорап укый торган намаз да бар. Никадәр генә сүксәк тә, боларның Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте икәнен онытмасак иде. Хәтта яңгыр яуганда кылынган догалар кабул булыр, диелә. Кар яуганда да: «Раббым, хәерле явым-төшемнәр булсын иде!» – дисәк, дөрес.

Су аккан тавыш, су агышы безне тынычландыра. Моның сере дә бар. Кәримдә: «Аллаһны зикер итү белән күңелләр тынычлана», – диелә. Ягъни су ага, җил исә, агач шаулый, кош сайрый икән, һәркайсы үзенчә Аллаһы Тәгаләгә тәсбих әйтә, аны зурлый. Су исә гел агып тора, димәк, ул һәрдаим зикер кылуда.

:: Суны исраф итү – гөнаһмы? Без судан ничек файдаланырга тиеш?

– Рәсүлебез (с.г.в.) үз хәдисләрендә суны исраф итмәскә куша. Хәзер душ, ванналар бар, мунча кирәбез. Анда да суны тиеш күләмдә генә кулланырга кирәк. Госел белән тәһарәтнең дә бер сөннәте – суны кадерләп тоту, исраф итмәү. Рәсүлебез (с.г.в.) безне шуңа өйрәтә. Суны эчкәндә дә дөяләр сыман эчмәгез, ди. Ягъни тончыгыр дәрәҗәгә җитеп, ямьсез итеп түгел, йотым-йотым гына. Мөселманнар өчен иң кадерле су – зәм-зәм суы бар бит әле. Аны без кыйблага карап, савыттагы суны өч өлешкә бүлеп, баскан килеш эчәбез. Ә гади суны, пәйгамбәребез кушканча, «бисмиллаһ» әйтеп, сулы савытны уң кулга тотып эчәргә кирәк.

pixabay.com

Су тәһарәт алу өчен дә кирәк. Су булмаса, балчык йә тузан белән тәһарәт алу мөмкин. Бу тәяммем дип атала.

:: Суга түкерергә, кече йомышны үтәргә ярыймы? Су янында сүгенергә дә ярамый дигәнне ишеткән бар.

– Аллаһы Тәгалә безгә табигатьне әманәт итеп бирде. Без шушы әманәтне дөрес итеп кулланырга тиеш. Суны пычрату, түкереп киту, йомышны үтәү – болар әдәпсезлек билгесе. Хәтта суга сүгенергә дә ярамый! Әйткәнемчә, җан иясенә бирелгән бу нигъмәтне Аллаһы Тәгалә олылап, кадерләп торырга кушты. Пәйгамбәребез (с.г.в.) яшәгән якта суга кытлык. Алар аны кадерләп, белеп тота торган булганнар. Ураза тотканнан соң да иң элек су белән, йә булмаса хөрмә җимеше белән авыз ачабыз бит.

:: Әби-бабайларыбыз су тулы савытларның өстен каплап тотарга дип өйрәтеп үстерде. Бу билгеле бер ышану гынамы, әллә дин шулай кушамы?

– Моны җен вә шайтаннар су эчмәсен өчен эшлиләр. Йә булмаса, пычрак төшеп, су пычранмасын өчен шулай итәләр. Суны эчкәннән соң савытны каплап куйсак та, хәерлерәк.

:: Коръән аятьләре укылган суны эчү хәерле гамәлме? Файдасы тия, диләр...

– Су терелтә торган үзлеккә ия, диелә Коръәндә. Авырган кешеләргә аны өшкереп бирәләр. Әйткәнебезчә, су янында сүгенергә дә ярамый. Аның шундый үзенчәлеге бар: ул мәгълүматны сеңдерә, истә калдыра. Коръән укылып, өшкерелгән су шифалы. Аннан файдаланырга кирәк.

Кулчатыр кыйссасы

Гыйбрәт ал!

Берәү базарда яңгыр астында кала. Аптыраганнан, кибет тоткан бер танышын күрә дә аннан кулчатырын биреп торуын сорый. Тегесе аһ-ваһ килеп булса да, кулчатырын бирә. Яңгыр туктамаган, шул сәбәпле беренчесе өенә кулчатыр белән кайтып киткән. Иртәгә исә ул кулчатырын кире хуҗасына илтеп тапшыра, рәхмәт әйтә.

Көннәрдән бер көнне болар кабат очраша. Кулчатыр хуҗасы:

– Теге көнне кулчатырымны бирмәсәм, ай-яй, хәлең ничек булыр иде икән? – ди.

– Чыланыр идем, – дип җавап кайтара танышы. Тегесенең кәефе кырыла, кулчатыр биреп торганына үкенә башлый.

Көннәр уза. Болар кабат очраша.

– Теге көнне кулчатыр бирмәгән булсам, ул яңгырда нишләр идең, ә? – дип, танышының башына суга кулчатыр хуҗасы.

Бу хәл берничә тапкыр кабатлана. Кулчатыр алып торган кеше инде ник сораганына да үкенә. Беркөн кабат очрашканда, теге бозык холыклысы:

– Әйт әле, дускай, теге көнне яңгыр астында нишләр идең икән? – дип сорый.

Тегесе исә һич җавап бирмичә, янәшәдәге буага сикерә. Аннан лычма су булып чыга да:

– Менә шундый булыр идем. Нинди бозык күңелле син! Кеше үзенең дусларына бер игелек тә кылмаска тиешме? Кеше булган кеше һәр эшләгән кечкенә игелеге өчен синең сыман интәшләренең «башына сугып» торса, кыямәт кубар. Биргәнең дә нәрсә – бер кулчатыр бит! – дип китеп бара.

Аллаһы Тәгалә мондый бозык, кара эчле дуслардан үзе сакласын!

Йәгез, бер дога!

Ишекләрне (эш урынында) ачып кергәндә укыла

«Әллааһүммә йәә мүфәттихәл-әбвәәб. Ифтәх ләнәә хайраль-бәәб. Әллааһүммәрзукънәә ризкан хәләәлән таййибән вә ризкан вәәсиган, бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин. Вә әнтә хайрур-раазикыйин».

Мәгънәсе: Әй, ишекләрне ачкан Аллаһым! Безгә хәерле ишекләрне ач. Аллаһым! Безгә хәләл һәм пакь ризыкларны ихсан әйлә, ризыгыбызны киңәйт, әй мәрхәмәтлеләрнең Мәрхәмәтлесе! Ризык бирүчеләрнең иң хәерлесе – Син.

Өч хәдис

«Мин сезгә ике нәрсә калдырам, шул ике нәрсәгә тотынсагыз, хак юлдан адашмассыз: ул ике нәрсә – Аллаһның китабы һәм пәйгамбәрнең сөннәте».

«Аллаһы Тәгалә әйтә: «Әй, колларым, белегез! Мин сезне уен-көлке өчен яратмадым, кирәксезгә дә яратмадым һәм сез кыла торган гамәлләргә игътибарсыз түгелмен».

«Кулыннан һәм теленнән башкалар бернинди дә зарар күрмәгән кеше – чын мөселман ул».

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ЧЫН ИР-АТ ШУНДЫЙ БУЛЫРГА ТИЕШ

Ватанны саклаучылар көне якынлаша. Шул уңайдан танылган ир-егетләрнең тормыш иптәшләре белән көчле затларга хас сыйфатлар, балачактагы һәм бүгенге идеаль ир-ат образы турында сөйләштек.

МИЛӘҮШӘ САБИРОВА:
«КЫЗЛАРЫМА ДА ДАНИР КЕБЕК ИР ТЕЛИМ»

– Минем өчен идеаль ир-ат образы ул – әтием. Кечкенәдән шулай. Кыз бала белән әти кеше арасында болай да үзгә мөнәсәбәтләр була бит инде, безнең аралар да электән бик җылы. Минем әти шундый игътибарлы кеше ул. Туган көн булсынмы, башка берәр бәйрәмме – барын да язып барып, матур итеп котлый белә. Элегрәк егетем белән йөри башлавыма бер ел тулганны да мин түгел, ул белеп тора иде (көлә). Шулкадәр бай гаиләдә үстем, дип әйтә алмыйм, ләкин әтием минем бар теләкләремне дә үтәргә тырышты. Телефонны да иң беренче миңа алып бирделәр, башкасын да.

Ә тормыш иптәшемә килгәндә, мин аның ниндидер сыйфатларына түгел, ә үзенә гашыйк булдым. Менә шулай 18 яшемдә үлеп гашыйк булдым да артыгын уйламый гына кияүгә чыктым. Ул чакта миңа җырчы Сергей Лазаревның тышкы кыяфәте ошый иде, ни өчендер Данирны да нәкъ менә аңа охшаттым. Әтием кочагында, аның игътибарын, мәхәббәтен тоеп үскән бала булгач, Данирның да шундый булуын теләдем, билгеле. Электән игътибарлы булды, дип әйтә алмыйм, ләкин хәзер үзгәрде ул. Беләсезме, миңа аның бар сыйфатлары да ошый, ләкин кешегә, үзе артында «чәйнәмичә», уйлаганын, теләгәнен туры бәреп әйтә белүен, беркайчан да берәүгә дә охшарга тырышмавын, ни генә булса да, хәлгә керә алуын аеруча хөрмәт итәм. Ир-атлар менә шундый булырга тиеш, миңа калса. Кызларыбыз да әтиләренә сокланып үсә. Алар да: «Әтием шикелле кешегә кияүгә чыгасым килә», – ди. Мин дә шулай булуын теләр идем.

РЕЗЕДА ӘХМӘТВӘЛИЕВА:
«АНЫҢ БЕЛӘН ҮЗЕМНЕ ТАШ ДИВАР АРТЫНДА КЕБЕК ХИС ИТӘМ»



– Нәрсәне дә булса күзаллап яши белмим мин. Шуңа бала чагымда, менә мондый кешегә кияүгә чыгам, дип хыялланып утырган чагымны бер дә хәтерләмим. Һөнәр белән дә шулай. Кайчан да булса үзем җырчы булырмын, нәкъ менә җырчыга кияүгә чыгармын, дип уйлап та карамадым. Тормышның үз җае бар бит. Фирдүскә килгәндә, ул – үз эшен гаять төгәл башкаручы, таләпчән җитәкче. Шуңа игътибар иткәнмендер. Фирдүснең эш сөючәнлеге, ярдәмчеллеге, балалар белән йомшак итеп сөйләшүе, кирәк чакта романтик була белүе, мине якларга, сакларга тырышуы – бик күркәм сыйфатлар. Аның белән булганда үземне таш дивар артында кебек хис итәм мин.

Гомумән, ир-егетләр гаиләсен, әти-әнисен, туганнарын хөрмәт итәргә, кадерләргә тиеш, минемчә. Үзе үскән һәм үзе корган гаиләне яклап, саклап яши белсен. Гаиләнең мул һәм тыныч яшәве дә ир-ат җилкәсендәдер дип уйлыйм. Уларның үсә, аларның кешеләргә хөрмәт белән каравын, тәмле телле, тәрбияле булуларын теләр идем.

РЕЗЕДӘ СӘЛӘХОВА:
«ӘЙТКӘН СҮЗЕ, КЫЛГАН ГАМӘЛЕ ӨЧЕН ҖАВАП ТОТА БЕЛСЕН»

2017–2020 елларда республикада универсаль спорт мәйданчыклары төзү программасы буенча модульле 41 чаңгы базасы булдырылган. 2021–2022 елларда Апас, Чүпрәле, Кама Тамагы, Теләчедә тагын дүрт база төзелгән. Һәрберсе кар көрәгеч, 100әр пар чаңгы һәм башка җиһазлар белән тәэмин ителгән. Соңгы елларда Әгерҗе, Нурлат, Яңа Чишмә, Кукмара, Биектау районнарында, Болгарда, Казанның Дәрвишләр бистәсендә 100 чакрымнан артык яктыртылган чаңгы юллары файдалануга тапшырылган.

Белгеч сүзе

Ринат АБЗАЛОВ, КФУ профессоры, биология фәннәре докторы:
– Физкультура дәресләрен хәзер тиешенчә үткәрмиләр, мин моны курыкмыйча әйтәм. Укытучы урамга алып чыга да туп ыргыта. Типкәне тибә, типмәгәне юк. Хәрәкәт җитмәсә, кеше авырый башлый. Хәзер менә чаңгыда шуарга була. Чаңгы – сәламәтлекнең нигезе. Мәктәпләрдә аңа игътибар гына түгел, чаңгысы да бетте. Ким дигәндә 30–40 пар әзерләп куярга кирәк. Дәүләт бу чыгымны гына күтәрә ала бит инде. Заманында, дәресләрне югалтмас өчен, мәктәп программасына чаңгы җитмәгән очракта, җәяү йөрергә дип керткән идек. Бу хәзер дә мөмкин. Чаңгы ки дә көнгә ким дигәндә 35–40 минут тау, урман кырыйларын ашыкмыйча гына әйләнеп кайт. Чаңгы шуган балалар авырмый, авырса да, чир тиз үтә. Беренчедән, саф һава. Икенчедән, йөрәккә, үпкәгә файдасы бик зур. Мин көн саен иртән чаңгы таягы алып, табигатькә чыгып китәм. Хәрәкәттә – бәрәкәт.

ИЛТӘБӘР БЕЛӘН ИЛЧЕ

Сүз дә юк, Идел Болгарстанында ислам кабул ителү турында сүз чыгуга, без ике таныш исемне искә төшерәбез. Беренчесе – Идел Болгарстаны дәүләтенә нигез салган Алмыш хан. Икенчесе – төбәктә рәсми ислам кабул итү тарихы белән бәйле Багдад илчелеге сәркатибе Әхмәд ибне Фадлан. Без алар турында ниләр беләбез соң? Гомумән, беләбезме? Тарих фәннәре докторы, профессор Фаяз Шәрип улы ХУҖИН безгә бу бөек шәхесләр турында янә бер кат искә төшерергә ярдәм итте.

Алмыш хан

IX гасыр ахыры – X гасыр башы Кара диңгез, Азов һәм Каспий буе далаларыннан Урта Иделгә күчеп утырган болгарлар тарихында мөһим этап булып тора. Инде ике йөз ел чамасы Идел-Кама төбәгендә яшәп, табигатенә яраклашып, утрак тормышка күнегеп өлгергән болгарлар һәм алар белән бергә күчеп утырган тугандаш суварлар, барсиллар, бәрәнҗәрләр тарихка Шилки исеме белән кереп калган илтәбәр (юлбашчы) кулы астында берләшәләр. Бу берләшү ничек башлана соң?

Кешелек җәмгыятенең борынгы община строеннан башлап кайсы гына чорын алып карасаң да, социаль тигезсезлек дигән күренеш күз алдына килеп баса. Бу – табигый хәл. Һәр җәмгыятьнең лидерлары була. Алар гади халык массасыннан – ыругдашларыннан, кабиләдәшләреннән – беренче чиратта физик яктан көчле булулары, ораторлык сәләте белән дә аерылып торганнар. Кабилә лидерлары да шулар арасыннан сайлап куелган. Шул ук юлбашчылар күршеләргә талау сугышлары да оештырганнар. Кулга төшкән байлыкны үзләренчә бүлгәннәр. Байлыгы булгач, юлбашчыларның яшәү шартлары да үзгәрәк була, әлбәттә. Байлыгын саклау өчен дружина да тота башлый. Дружинаны, эреле-ваклы чиновникларны туендыру өчен халыктан салым җыя башлыйлар. Шул рәвешчә дәүләт барлыкка килә. Дәүләтнең идарә органнары, алар урнашкан нигытмасы һәм инде хакимгә (ханга, патшага) буйсынучы халык яши торган территориясе була.

Илтәбәр Шилки чорында төрки кабиләләрдән торган нәкъ шундый дәүләт берләшмәсе формалаша башлый. Аның башында болгарлар тора. Әлеге процесс Шилкинең улы Алмыш хан чорында тәгәлләнә. Алмыш ханны тарихчылар Идел Болгарстаны дәүләтенең беренче идарәчесе – илтәбәре дип санийлар. Ләкин шуны истә тотарга кирәк: X гасыр башында әле ул – Хәзәр каһанына буйсынган өлкә генә. Алмышның улы каһан сараенда тотык хәлендә яши, ә кызы каһанга көчләп бирелгән була. Әмма Алмыш хан бу бәйлелектән котылуның төрле юлларын эзли, дәүләтнең мөстәкыйльлегенә омтыла, тиздән әлеге бәйлелек формаль бернәрсә генә булып кала.

Алмыш хан, Хәзәр каһанының рөхсәтен дә сорап тормыйча, үз исеменнән акча суктыра башлый. Беренче болгар акчалары, нумизмат галимнәр әйтүенчә, 902–908 еллар аралыгында сугылган. Археологик казу эшләре вакытында килеп чыккан әлеге акчалар – дәүләтнең мөстәкыйльлеген раслаучы кыйммәтле табылдыклар. Әлеге акчаларда Алмыш ханның мөселманча исеме күрсәтелгән – Җәгъфәр ибне Габдаллах. Димәк, шул чорда ук инде болгар идарәчесе ислам динен кабул иткән булып чыга.

Болгар – сәүдәгәрләр иле. Яз ахырларына таба Идел буйлап Болгар ярминкәсенә төрле илләрдән сәүдә кораблары килгән. Аларны, гадәттә, хан үзе каршы алган, чөнки сатуга алып килгән товарларның уннан бер өлеше дәүләт казнасына кергән. Хәзәрләрдән килгән сәүдәгәрләргә дә берниндн ташламалар ясалмаган.

Алмыш хан дипломатия өлкәсендә дә уңышлы адымнарын башлый: Урта Азия илләре белән тыгыз мөнәсәбәтләр, беренче чиратта сәүдә элемтәләре урнаштыра, угызлар берләшмәсенең Әтрәк исемле бер кабилә башлыгына үзенең кызын (кайбер чыганаклар буенча сеңлесен) кияүгә бирә. Аның иң зур уңышы – әлбәттә, Гарәп хәлифәлеге белән илчелекләр алмашу.

921 елда Алмыш хан Багдадка Габдулла ибне Башту җитәкчелегендә илчелек җибәрә. Аның төп бурычы Багдад хәлифе әл-Мөкътәдир белән Хәзәр каһанына каршы берлек төзү була. Бу хакта Алмыш ханның Багдад хәлифенә язылган хатында турыдан-туры әйтелә. Хан «дошманыннан саклану өчен» крепость-шәһәр төзүдә ярдәм сорый һәм Болгарга ислам дине белгечләрен дә җибәрүләрен үтенә. Сөйләшүләр барышында әл-Мөкътәдир ризалыгын белдерә. Аның төп максаты болгарлар арасында Хәлифәт йогынтысын ныгыту, ислам дине таралышын төньяк тарафларга кадәр киңәйтү, хәзәрләргә каршы көрәштә Алмыш ханның булышлыгына ирешү була.

Алмыш хан Багдад илчелеген Болгар җирендә 922 елның 12 маенда каршылый. 16 майда тантаналы шартларда ислам дине дәүләт дине буларак кабул ителә. Шуңа да игътибар итәргә кирәк: бу чакта Хәзәр каһаннары яһүд динен тотканнар. Алмыш хан исә, дөресрәге, инде ике дистә ел элек үзен мөселман дип игълан иткән Җәгъфәр ибне Габдаллах, алардан рөхсәт тә сорап тормыйча, илдә ислам динен рәсмиләштерә. Бу факт та – Болгар дәүләтенең Хәзәр каһанлыгыннан номиналь рәвештә генә бәйлелектә булуына ишарә.

X гасыр башларында Болгар илендә Болгар, Биләр, Сувар кебек исемнәре елъязмаларда теркәлеп калган беренче шәһәр-калалар барлыкка килә. Эреле-ваклы авыллар турында искә дә алып торасы түгел. Икенче төрле әйткәндә, ярымкүчмә болгарларның җирләшүе, ягъни тулысынча диярлек утрак тормышка күчүе Алмыш хан чорында тәгәлләнә. Болгар иленең киләчәктәге тотрыклы үсешенә дә нәкъ менә Алмыш хан идарә иткән чорда ныклы нигез салына.

Әхмәд ибне Фадлан

Алмыш хан Әхмәд ибне Фадлан белән 922 елның 12 маенда очраша. Ул – Багдад илчелегенең сәркатибе, хәлифә сарае хезмәтчесе. Ибне Фадлан бик укымышлы кеше була, шуңа күрә аңа юлъязмалар алып бару һәм илчелекнең эш нәтиҗәләре турында исәп-хисап тоту эше тапшырыла. Хәзерге көннәргә кадәр сакланып калган Ибне Фадлан язмалары («Рисалә») болгарларның X йөз башы тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтен ярыйсы гына тулы итеп күз алдына китереп бастырырга мөмкинлек бирәләр.

16 майда үткән тантаналардан соң Алмыш хан Багдад кунакларын һәм үзенең якыннарын мең кеше сыйдырырлык юртасына мәҗлескә чакыра. Кунакларны кабул итү йоласын Ибне Фадлан үзенең китабында җентекләп тасвирлый. Шул ук вакытта Болгар патшасы турында да беренче тәэсирләрен бәян итә: «Алмыш – ярыйсы гына тулы гәүдәле, инде корсак та үстерә башлаган урта яшьләрдәге боеручан бер хакимдер», – ди. Гомумән алганда, Багдад илчеләрендә ул уңай тәэсир калдыра. Шул ук вакытта каршылыклар да булмый түгел.

Бер-ике көн үтүгә, Алмыш илчелек сәркатибен үзенә чакыра һәм аны утлы табага бастыра: «...әл-Мөкътәдир хәлифәнең хатында телгә алынган һәм син миңа тапшырырга тиешле 5000 динарны кая куйдыгыз? – дип җикеренә хан. – Ул акчаларны мин кальга (крепость) төзегәндә сарыф итәргә исәп тота идем». Алмышның мондый кыланмышыннан куркуга төшкән Ибне Фадлан аңлатып бирә: Мөкътәдирнең әлеге динарларны бирергә тиешле бурычлы кешесе бөлгән булып чыга, һәм илчелек, ул яши торган шәһәрдән буш кул белән чыгып китеп, юлын дәвам итәргә мәҗбүр була. «Дөресен әйткәндә, казнамда ул каланы гына төзерлек алтын-көмешләрем җитәрлек, – ди Алмыш моңа җавап йөзеннән. – Хәлифәнең динарларын бу эшкә хәерхаһлык, Аллаһның ризалыгы билгесе итеп кенә кабул итмәкче идек» .

Берничә көннән бу аңлашылмаучылык бөтенләй онытыла. Багдад илчелеге килү шатлыгыннан башы күккә тигән Алмыш хан Ибне Фадланны һәм аның юлдашларын халык арасына алып чыга, ил белән таныштыра, болгар бабаларының элеккедән калган гореф-гадәтләре турында сөйли. Ибне Фадлан Болгарга килгән рус-варяглар белән дә якыннан танышу бәхетенә ирешә. Күзәтүчән һәм искиткеч хәтергә ия сәркатип боларның барысын да көндәлек дәфтәренә «язып» бара. Илчелек Болгар илендә берничә ай була, көзгә таба, «көннәр кыскара башлагач», кире кайтыр юлга чыгалар.

Багдадка кайтып җиткәч, Әхмәд ибне Фадлан, юлъязмаларны тәртипкә салып, күргән-белгәннәрен яңадан исенә төшереп, әл-Мөкътәдир өчен хисап әзерли. Бәхеткә, бу язмалар юкка чыкмаган. Аларны 1923 елда Иранның Мәшһәд шәһәре китапханәсендәге кульязмалар бүлегендә Төркиядә яшәүче эмигрант тарихчы Әхмәдзәки Вәлиди табып ала һәм 1939 елда Германиянең Лейпциг шәһәрендә немец телендә бастырып чыгара. Ибне Фадлан кульязмасы Андрей Ковалевский тәрҗемәсендә 1956 елда Мәскәүдә дә нәшер ителә. Әнвәр Хәйри тарафыннан әзерләнгән татарча тәрҗемәсе 2013 елда дөнья күрә.

Әхмәд ибне Фадлан «Сәяхәтнамә»се Идел болгарлары, аларның күршеләре башкорт, хәзәр, угыз һәм дә рус-варяглар тарихын өйрәнүдә кыйммәтле һәм ышанычлы тарихи чыганак булып тора.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

5 САБЫЕ БЕЛӘН ТОЛ КАЛГАН ИР:

«ХАТЫНЫМ, БАЛАЛАРНЫ ТАШЛАМА, ДИДЕ»

Апас районының Сатмыш авылында яшәүче 33 яшьлек Ринат Хаҗипов биш баласы белән тол калган. Бер атна элек хатыны Раиса мәңгелеккә күзләрен йома. Ринатның иң олы баласына – 13, кечкенәсенә әле 11 ай гына. Ир хатынын югалту хәсрәте белән яна, сабыйларга әниләре кирәк!

Ринат Хаҗиповның шәхси архивыннан

– Без Башкортстанның Әлшәй районыннан. Әле менә Раисаны җирләп, Апаска кайтып барыш. Үзенең васыяте буенча туган авылына җирләдек. Хатынымны соңгы юлга озатыр өчен районнан машина бирделәр. Биш балам белән юлга чыгып киттем. Сабыйларым кечкенә булса да, әнисез калганнарын аңладылар инде. Әниегез хәзер безнең йөрәктә яшәячәк, дидем. Аларны да зиратка алып бардым. Үсә төшкәч, соңгы юлга нигә бергә озатмадык, дип йөрәкне өзәрлек булмасын, – ди Ринат. – Хатынымның Татарстанда яшисе килгәч, ике балабызны алып, Казанга килеп урнашкан идек. Аннары ана капиталына йорт сатып алып, Апас районына күчендек. Бу якларны бик яратып, матур гына яши башладык. Тик гомер юлын ахыргача бергә үтәргә насыйп булмаган икән. Туган ягымда каласым килмәде, торган җиребезгә ияләндек. Үз өебезгә кайтасыбыз килә.

Раисага бары 33 яшь кенә була. Моңарчы авырыйм дип бер дә зарланмый ул. Тупырдап торган биш бала таба. Әле кечесен тапкач та, сәламәтлегенә зарланмый. 2021 елның декабрь ахырында кинәт ашказаны авырта башлагач та, катлаулы чир икәнен белештермиләр.

– Хатыным бик көчле авыртудан зарланды. Ашказаны тирәсе түзеп булмаслык итеп кисә иде. Район хастаханәсенә киттек. Андагылар икенче көнне үк Казанга җибәрде. Хатыным Республика клиник хастаханәсендә ай ярым ятты. Гыйнвар башында катлаулы операция булды. Раисаның үт куыгын, ашказаны асты бизен алып ташладылар. Бар да артта калган кебек иде, – дип искә ала Ринат.

Февраль башында Раисаны өенә кайтаралар. Хатынының хәле авыр икәнен иренә берәү дә әйтми. Ринат аның терeләсенә өметләнә. Хатын үзе дә берни сиздерми. Тик өйгә кайткач, авырту кабат көчәя. Ашаудан калган Раиса соңгы теләген җиткерә: «Әгәр терелә алмасам, балаларны ташлама».

– Мин ул чакта ул сүзләрне сызлануга түзә алмаганга әйткәндер дип уйладым. Менә хәзер аңладым инде – Раиса китәсен белгән икән. Бәлки Казан табибләры үзенә дә әйткәндер, – ди Ринат. – Мин аны иртәгәсен Апас хастаханәсенә алып киттем. Хәле начарлангач, төнлә аны реанимациягә күчерделәр. Иртәнге җидедә берничә минутка янына кертеләр. Ярты сәгатьтән хирург чакырып алып, хатынымның үлгәнен җиткерде. Шунда бар тормышым күз алдыннан узды. Уемда сабыйларым иде. «Ничек яшәрмен, нигә шулай иртә киттең?» дигән сорау белән җанымны телгәләдем. Тик елап утырып булмады. Өйдә биш балам көтә бит.

Ринат, балаларымны үзем үстерәчәкмен, ди. Тиздән хатынының туганнары, үзенең апалары да Апаска киләчәк.

– Ничек тә яшәрбез әле. Бала күрмәгән ир түгел мин. Алла боерса, бу хәсрәтне бергәләшеп җиңеп чыгарбыз дип уйлыйм. Район кешеләре ярдәм итә, җитәкчеләр ташламый. Әле менә фатирга чират торабыз. Балалар бәхетенә анысы да булып куйса, тормыш җиңеләер иде. Дөньяның бар яме – сабыйларымда. Мин аларны кеше итәргә, аякка бастырырга тиеш. Балалар буй җитмичә, үзем турында уйламыйм да, – ди ул. – Никадәр тырышсам да, әниләре була алмам. Әмма бар җылымны, назымны бирермен. Газиз балаларыма карагач, күңелем тула. Тик еларга ярамый. Раиса шатланып ятсын өчен, без матур итеп яшәргә тиеш. Ышанам – бар да яхшы булыр.

Ринат «М12» оешмасында эретеп ябыштыручы булып эшли икән. Эшендәгеләр дә матди ярдәм күрсәткән, Сатмыш авыл халкы да булышкан. Әмма аңа биш баланы аякка бастыру җиңел булмаячак. Әнә шуңа да авылдашлары Ринатка ярдәм итүне сорый.

Хаҗиповлар гаиләсенә ярдәм итәргә теләүчеләр өчен Ринат Рөстәм улының «Альфа-Банк» картасы номеры: 4584432842509128. Карта 89520472576 телефон номерына бәйләнгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТЕЛӘК БУЛМАСА, КУЛ ГЫНА ҖИТМИ

Әтнә районының Олы Мәңгәр авылында гомер итүче 90 яшьлек Мәсхүт Шакиров 35 елдан артык сыңар кул белән яши. Әмма сау-сәламәт кешеләрдән бер җире дә ким түгел. Бер кулым юк дип тормый – печәнен дә чаба, утынын да яра, карын да көри.



Кулын комбайнда эшләгәндә өздерә ул. Әзмәвердәй ирнең гарипләнүе гаиләсе өчен дә зур хәсрәт була. Якыннары терәк була. Балалары да, әти, сиңа ярамый, саклан, дип кенә тора. Әмма ул бирешми. Әкренләп бер кул белән яшәргә өйрәнә.

– Гариплекне сорап алмыйсың. Мин дә болай булыр димәгән идем. Күрәчәк булгандыр инде. Кимчелегем белән килешмәдем. Башка җирләрем сау булгач, кул өчен артык исем китмәде. Яшәрмен әле, дидем. Шөкер, бара бит дөнья. Теләк кирәк. Ул булса, таулар күчерәсең икән ул. Мин әле дә үземне ике куллы итеп хис итәм, – дип сөйли Мәсхүт абый.

Егет күңелле бабай булып чыкты Мәсхүт абый. Протезны «запас кул» дип йөртә. Эшкә кия торганы да, рәешкә дигәне дә бар икән. Кулы булмаганга бер дә читенсенми. Киресенчә, ул язмыш сынавын дөрес кабул итүенә, дин юлына китеп, игелеклән кылып яши алуына сөенә.

– Хатыным Фаимә 1990 елны яман чирдән үлеп китте. Без аның белән бик матур яшәдек. 3 малай, 2 кыз үстердек. 33 ел бергә яшәгән хәләлемнең үлеме авыр тәэсир итте. Җанымны басар өчен мин догалар укый башладым, әкренләп дингә якынайдым. Шул чакта Казанда яшәүче ялгыз бер хатын белән танышттым. Балаларым да каршы килмәде. Мин шәһәргә күчтем. Бик яхшы кеше булып чыкты Мөршидә. Кызганыч, аның белән нибары 14 ел гына яшәп калдык, – дип сөйли Мәсхүт абый.

Икенче хатынының ашларын уздыргач, ул кабат авылына кайтып китә, ә Мөршидә апаның балалары белән әле дә аралашып тора.

– Язмышка ни язылганын беребез дә белми. Мин дә болай озак яшәрмен димәгән идем. Аллаһы Тәгалә юлында булу яшәргә көч бирә. Сабырлык өсти. Әле бит мин олы яшьтә дип тик утырмыйм. Улым белән киленем өйдә булмаганда, вак-төяк эшләрне эшләп куям. Алар кунакка китсә дә, миңа ышанып йортны калдырып китәләр. Тик утырырга күнекмәгән мин. Хәрәкәт кирәк, – ди ул. – Картлыгым бәхетле үтә. Улым белән киленем тәрбиясендә кирәкле булып яшим. Алар хөрмәт итеп тора. Биш баламның тормышына сөенеп яшим. Аллаһы Тәгалә кулымны алса да, бәхетне өеп бирде миңа. Шуңа күрә һәр сынауны дөрес кабул итеп, сабыр итәргә кирәк. Ә калганы була икән!

Игълан тактасы

Кемгә кирәк?

***

13–14 яшьлек кыз бала өчен җәйге киемнәр бар. Кирәк кеше редакциягә шалтыратсын иде.

Лилия ӘХМӘТОВА.
Казан

***

Яхшы хәлдәге, берничә тапкыр гына киелгән 48 үлчәмдәге кышкы тун, 39 үлчәмдәге кышкы аяк киеме бирәм.

Гөлназ ХӘКИМОВА.
Чаллы

***

42–44 үлчәмдәге хатын-кыз киемнәре бирәм. Бер дә киелмәгән җәйге күлмәк, кофта-чалбарлар бар.

Регина ДАВЫДОВА.
Казан

***

Балалар өчен бер капчык йомшак уенчыклар бар. Кемгә кирәк, хәбәр итегез.

ГӨЛФИЯ.
Казан

КӨРӘШЕП КИТЕП БАРДЫ...

Аксакал рәссам Зөфәр Гыймаев та арабыздан китте. Тукай кебек туры сүзле, Урманче кебек кыю, кешелекле, гадел, чын мәгънәсендә көрәшче. «ВТ»га бирелгән соңгы интервьюсында ул үзен бәхетле кеше дип әйткән иде. Сынаулар килеп чыкканы, алар белән көрәшергә көч тапканы өчен. Хәзер кем генә сынаулар килеп чыкканына рәхмәт әйтә белә икән? Ә ул рәхмәтле кеше иде.



Зыялы. Гадел. Кешелекле

Остазлары белән хушлашырга «Казан нуры» мәчетенә рәссамнар шактый килгән иде. Алар аны, гадел булды, диделәр. Без нинди булсак та, төрле төркемнәргә таралсак та, барыбызны да яратып кабул итте, дип искә алдылар. Рәссамнарның биш бүлеккә таркалуы, татар рәссамының татар рәссамына каршы көрәшүе аның җан ярасы иде. Казандагы килбәтсез һәйкәлләргә дә җаны әрнеде. Ул аны интервьюларда да әйтә килде. Билгеле, бу фикерләре өчен башыннан сыйпамаганнардыр.

> «Чын рәссам беркайчан да матди яктан иркен яши алмады. Чөнки аның үзен күрсәтергә, кирәкле кешеләрнең кулын кысарга вакыты юк. Ул иҗат белән яши, төшләрендә дә иҗат белән саташа. Байлар исә иҗатны производствога әйләндерә. Кайчак хәтта гаилә подрядына әйләнеп китә: берсе һавасын ясый, икенчесе – җирен... Галереяда андый эшләр күп, арзан булгач, алучысы да бар. Яхшы рәссамнар бик аз».

Россия кинематографчыларының Татарстан бүлеге рәисе Илдар Ягъфәров аның белән Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе комиссиясендә танышуы хакында искә алды:

– Шулкадәр ачык, кешелекле, гадел кеше. Чын татар зыялысы. Аның тәнкыйте дә һәрвакыт урынлы булды, әйтәсе сүзен кешенең аяктан екмыйча әйтә белде. Татарстанга бөтен дөньяга танытырлык бай мирас калдырды. Аның әсәрләре Камал театрында да, «Хәзинә»дә дә шактый. Камал театрындагы картинаның берсе – Марсель Сәлимҗанов портреты.

Зөфәр абый Камал театрына аерым бер хөрмәт белән карый иде. Театрның Туфан абыйның портретын ясарга заказ бирүен дә аерым бер җылылык белән искә алуы хәтердә. Башта бу эш башка рәссамга йөкләнгән булган, Туфан абый исә аңа рөхсәт бирмәгән. Зөфәр абыйны «Әбигә хат килде» дигән картинаның авторы булуын белгәч сайлаган. «Килеп керде остаханәгә, бергәләп чәй эчтек, сөйләшә башладык. Туфан абый берзаман кыбырсый башлады. Аннан соң түзмәде, Зөфәр, син кайчан эшли башлыйсың соң, дип сорады. Мин, сез ишектән килеп кергәч эшли башладым, дип җавап бирдем. Картина аңа ошады, алырга исә үзе түгел, Шамил Закиров белән Марсель Сәлимҗанов килде. Шамил абый, менә бу төше килеп бетмәгән, ахры, дип сүз башлаган иде, Марсель абый көчле тавышы белән: «Әйбәт!» – дип пичәт сукты. Үзе ошаттымы, ди. Ошатты, дип җавап бирдем. Башын чайкап торды-торды да: «Мин сиңа үземне ясарга рөхсәт итмәс идем... Кешеләрнең эчемдә ни ятканын белүләрен теләмәс идем. Син бит Туфанның бөтен эчке дөньясын, авыл агаена хас булган саранлыгына кадәр чыгарып салгансың», – диде. Марсель белән бу вакыйгага кадәр үк аралаша башлаган идек инде. Аны яратмаучылар да шактый, әмма миңа аның көчле рухлы булуы бик ошый иде. Марсель гади кеше күрмәгәнне күрә белә, ышандыру, үзе артыннан ияртү сәләте зур. Искитмәле гадел кеше», – дип сөйләгән иде. Зөфәр абый, аның болай формалашуына спорт та тәэсир иткәндер, дип фаразлады. Үзе дә спортны ярата, спорт мастерына кандидат иде дә бит әле. Марсель Сәлимҗановның портретын да ясый ул. Режиссер портретны үзе генә күреп өлгерми, фанилык белән араны киңәт өзә...

Зөфәр абыйның Салих Сәйдәшев, Сара Садыйкова, Хәсән Туфан, Камал театрының күпчелек артистлары портретларын да искә төшерик. Саный китсәң, бихисап бит алар. Портрет геройларының берсе – Татарстанның халык артисты Дания Нуруллина да бар иде озату чарасында. Алтмыш яшенә рәсемен ясавын искә алды:

– Дүрт ай утырдым остаханәсендә. Ул сөйләшә-сөйләшә синең эчке дөньяңны ача, аны картинада чагылдыра белде. Күз карашларына кадәр төгәл бит. Сәхнәгә алып менгәч, тамашачы аһ иткән иде. Техниканы аны бөтен кеше үзләштерә ала, ә рәссам булып туарга кирәк. Зөфәр чын рәссам иде. Кабатланмас кеше иде. Күңеле тулы кояш, җылы...

Рәссам булу – язмыш

Ул шулай дип әйтергә ярата иде. Дүрт яшеннән рәсем ясавын, очарга хыяллануын, рәсемнәрендә гел очышны сурәтләвен елмаеп сөйләве гел күз алдында. Зөфәр абыйны көрәшче дип әйттек. Ә бит аңа кечкенәдән үз урыны, хәтта мәктәбе өчен дә көрәшергә туры килгән.

> «Рәссам булачагымны башлангыч сыйныфтагы укытучым Мария Павловна Дәминова аңлады. Әнигә, балагыз рәссам булачак, дип әйтте. Мин мәшһүр 39 нчы инглиз мәктәбендә укыдым. Монда беренче сыйныфтан ук инглиз теле дәресе керә, рус теле тирәнтен өйрәнелә, татар теле, факультатив булып, 7 нче дәрес итеп билгеләнә иде. Ул вакытта башкалар кайтып китә, татар балалары дәрескә кала. Ирексездән телгә карата нәфрәт барлыкка килә. Мин тырышып укыдым, әмма өйдә аралашу күбрәк урысча булды. Өй турында сүз чыккач, шунысын да әйтик, әти, сугыш ветераны, үтә туры сүзле, гадел булды. Шул сыйфатлары аркасында үзе дә бик нык кыйналды. Хәтта гаиләбезгә Казаннан Үзбәкстанга китәргә һәм анда күпмедер яшәргә туры килде. Укытучым да бик гадел иде. Бу мәктәпкә эләгүе бик читен, анда түрәләр үз балаларын урнаштырырга тырыштылар. Шул сәбәпле мин кабул ителгән балалар исемлегеннән сызып ташланган да булганмын. Укытучы мәктәп директорына, беренче чиратта исемлекне түрәләрдән чистартыгыз, дигән һәм мине кабат язып куйганнар».

Очу дигән балачак хыялы турында да искә алуыбыз очраклы түгел. Очасы килүе аны алты яшендә самолетта «куян» булып очуга да этәргән бит. Әнисе белән апасы аэропортта сөйләшеп торган арада шыпырт кына трап куелган самолетка менеп китә ул. Янына кызмача пассажир утыра. Балага әллә ни игътибар итми, каешын эләктерә дә, йоклап та китә. Шуннан соң Зөфәр апасын эзләп таба. «Апа белән бер-бер артлы ике самолетта очтык. Ул, нишләптер, аэропортта ук әнигә, Зөфәр минем белән, дип, телеграмма сукмаган. Барып җиткәч, берничә көн үткәч кенә хәбәр иткән. Әни, бичаракай, мине урлаганнар дип уйлаган булган икән инде. Мин исә, әни каршында гөнаһымны аз булса да киметермен дигән ният белән акча эшләп, Сәмәрканд базарыннан биш сумга ефәк яулык алып кайттым...» – дип сөйләгәне истә. Хәер, гаилә Зөфәр абый өчен бик зур мәгънәгә ия иде. Картиналарында да чагыла алар. Мәшһүрләреннән бабасы Шафигулла портреты күз алдында. Хатыны Гүзәл, кызы Айгөл, улы Әнвәр дә – аның илһам чыганаклары, терәге. Хушлашуга килгән якын дуслары Гүзәл ханымга башларын иеп рәхмәт әйттеләр. Яман чир белән сигез ел буе көрәшергә көч табар өчен тылның нык булуы кирәк, ди иде бит үзе дә.

«Миннән бүләк беләзек булыр...»

Хатыны Гүзәлгә, үлеменә бер көн кала, ул әнә шулай дигән:

– Зөфәр – көчле рухлы кеше. Нинди куркыныч авыру белән көрәште бит! Ул шулкадәр яшәргә тырышты, ахыргача, яшим әле мин, дип безне дә, үзен дә ышандырырга тырышты. 14 февральдә туган көнем иде. Өзелмәсә ярар иде, дип курыктым. Зөфәр улыбызны көтте. Ә ул 15 февральдә кайтырга тиеш иде. Көтеп җиткерде... Мине туган көнем белән котлады. Мин сиңа беләзек алдым, ул почта белән килер, диде. Соңгы бүләге шул булды. Яшәү кадерен дә, кеше кадерен дә белә торган зат, җаваплы ир, кайгыртучан әти иде.

Улы Әнвәр исә әтисенә көтеп җиткергәне өчен рәхмәтле:

– Әти безнең өчен бөтен эштә дә үрнәк булды. Дисциплина яратты, бездән дә шуны таләп итте. Кешенең тормышы заяга үтәргә тиеш түгел дип әйтә иде. Ул нәрсәләр белән генә кызыксынмады! Безгә дә аның кызыксынучанлыгы, эзләнүчәнлеге күчкән. Мин дә, аның кебек, спортны, иҗатны, логик уеннарны яратам... Мин аңа барысы өчен дә рәхмәтле. Мине көтеп җиткергәне өчен бигрәк тә. Күне буе сөйләштек, җан биргәндә янында булдым.

Хушлашырга кеше шактый җыелган иде. Ә мин исә, әгәр ул ясаган портретларның геройлары барысы да хушлашырга килгән булса, мәчет тирәсендә сыңар аякта басып торырга да урын булмас иде, дип уйлап куйдым. Ул зур залларга лаек, ул беренчеләр озатуына лаек, дигән фикер күңелне әледән-әле бимазалый. Хәер, Зөфәр Гыймаев күрсәтеп эшли торган кешеләрдән түгел һәм ул мондый шартлылыкларны кабул итмәс тә иде. Тыйнак яшәде, тыйнак китте. Яратып яшәде, яратып китте. «ВТ» газетасында да аның эзе калды. Картиналарыннан календарь чыгардык, аның белән бергә беренче хатын-кыз рәссам Галия Рахманкулованың кызын эзләдек. Барысы да истә.

Зөфәр абый Казанның «Курган» зиратында җирләнде.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ



ГЫЙМАЕВ ЗӨФӘР ФОАТ УЛЫ

(09.01.1951 – 15.02.2022)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Җәмәгать эшлеклесе, Россия Федерациясенең атказанган рәссамы Гыймаев Зөфәр Фоат улы 15 февраль көнне 72 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Зөфәр Гыймаев 1951 елның 9 гыйнварында Үзбәкстан ССРның Наманган шәһәрендә дөньяга килә. 1970 елда Казан сәнгать училищесын тәмамлый. Шуннан соң И.Е.Репин исемендәге Ленинград сынлы сәнгать, скульптура һәм архитектура институтында (1976 елда), СССР сәнгать академиясендә (1980 елда) белемен чарлый.

Зөфәр Гыймаев 1976 елда Казан сәнгать училищесында укыта башлый. Соңыннан үзе үк оештырган «Бип» пантомима студиясенә җитәкчелек итә. 1997 елдан, сынлы сәнгать белән шөгыльләнүен дәвам итеп, 2 нче татар гимназиясендә һәм цирк мәктәбендә укыта.

2001 елдан ул үзенең иҗат эшчәнлеген Татарстан Республикасы Рәссамнар берлегендә алып барды. 2008 елда Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге рәисе итеп сайланып, 2020 елга кадәр шушы вазыйфада эшләде.

Зөфәр Фоат улы Татарстанның әйдәп баручы сынлы сәнгать осталары исәбендә булды. Тематик картина, портрет, пейзаж, натюрморт жанрларында эшләде. Ул – «Әбигә хат килде» (1979), «Кичке автобуста» (1980), «Өч ай» (1997), «Татарстан акробатлары» (1979), «Икәүләшеп чәй эчү. Язучы Фәнис Яруллин һәм аның хатыны Нурсөя ханым» (2000) кебек искитмәле картиналар, «Күкидә кич» (1978), «Өмбе авылында көз» (1982), «Татар сөлгесе белән натюрморт», «Иске каһвә савыты белән натюрморт» (икесе дә – 1978 елда) кебек лирик пейзажлар авторы.

Аның күпкырлы иҗаты тирән эчтәлекле, хисле булуы белән аерылып торды. Хезмәтләре күп тапкыр халыкара, Советлар Союзы, Россия һәм республика күләмендәге күргәзмәләргә тәкъдим ителде.

Рәссамның әсәрләре Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, В.И.Суриков исемендәге Сынлы сәнгать музеенда (Красноярск ш.), Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, шулай ук Россия һәм чит илләрдә шәхси коллекцияләрдә урын алган.

Зөфәр Гыймаевның осталыгы югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – «Россия Федерациясенең атказанган рәссамы», «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе», «Татарстан Республикасының халык рәссамы» мактаулы исемнәре. Рәссам Татарстан Республикасы әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең портретлары сериясен булдырган өчен Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Зөфәр Фоат улы хезмәт сөючәнлеге, кешеләргә карата ихтирамлы мөнәсәбәте, үз эшенә иксез-чиксез тугрылыгы белән аерылып торды.

Халык рәссамы, талантлы шәхеснең якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. Миңнеханов, М.Ш. Шәймиев, Ф.Х. Мөхәммәтшин, А.В. Песошин, Ә.Ә. Сәфәров, В.Г. Шәйхразыев, И.Х. Әюпова, И.Р. Метшин, А.Х. Шиһабиев

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, Россиянең атказанган, Татарстанның халык рәссамы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

Зөфәр Фоат улы Гыймаевның

вафат булуы сәбәпле, туганнарының һәм дусларының авыр кайгысын уртаклаша. Ходай сезгә хәсрәтегезне күтәрә алырдай көч, сабырлык бирсен!

РАВИЛӘ ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ

ЯЛАНТАУГА АЙ КУНГАН

(БӘЯН)

< Ахыры. Башы 2021 елның 10 декабрь, быелның 21, 28 гыйнвар, 4, 11 февраль саннарында

Гөлҗиһанга Хәния кушылды:

– Мин дә шунда идем, абый. Рәфыйк үзе гаепле ул. Гел Сәетне кыйный. Аның бит әнисе дә, әтисе дә юк. Ник кыйный ул Сәетне? – дип, Хәния елап җибәрде. Аңа Гөлҗиһан да кушылды. Сәетнең дә күзләреннән яшь ага иде.

– Барыгыз, кайтыгыз, – диде Маһинурга директор.

– Ә сез бүген миңа кирәгез, – диде директор, Нураниягә усал караш ташлап. Сәетне кочаклап торган укытучы яшьле күзләрен мәктәп бакчасына төбәде.

Нураниягә соңгы кисәтү ясадылар. Тагын шушы хәл кабатланса, мәктәптән куу белән янадылар.

Шул төнне беренче тапкыр йөрәк өянәге тотты хатынны. Балалары авылның фельдшеры Нюрага чаптылар.

«Кизү, җаным, кизү бу» дигән диагноз куеп, кешеләрне тынычландыручы бу марҗа хатыны авыл халкы өчен иң зур профессор иде. Ул килеп керсә, инде үләргә яткан авыру да терелеп киткән сыман була. Нюра апага каян килгәндер кешене юата белү сәләте? Ходайдандыр. Шушы хәлдән соң мәктәптә узган һәр педсоветта бәйләнде директор укытучыга. Педсоветның ахыры Нураниянең йөрәк өянәге белән тәмамлана торган иде. Дәресләренә кереп йөдәтте. Үзе кермәсә, уку-укыту эшләре мөдирен кертте.

Педсовет буласы көнне балалары йөрәкләре алынып көттеләр. Кышын карга бата-чума, язын-көзен су ерып Нюра апаларына чабу өчен, һәрвакыт әзер булып тордылар.

* * *

…Сәет таң атканчы йоклый алмады. Күз алдына гарьләнеп үткән бала чагы килде. Әй, чиләнеп тә карадылар соң бабасы белән. Сыерга печән җыю дисеңме. Ызаннарда сусылланып баш төртә башлаган әрекмәннәрдән башлап, кукуруз, алабута, эт әчәгесе, билчән, зәңгәр чәчәк үсеп киптерү дисеңме. Ярый ла аны капчыкка тутырып алып кайтканда, председатель күрмәсә. Ул Сәеткә бигрәк тә каныга. Улының бер як бите ямьсезләнеп, кап-кара җөй эзе калды. Шуның үчен алуы бугай. Әллә инде малайның буйга тартылып, әнисенә охшап баруы ачуын чыгарамы? Сәетнең күңелендә беркайчан да «бу – минем эти бит» дигән хис уянмады. Бабасының: «Шул мөртәт кенә җитте кызымның башына», – дип әрни-әрни әйткән сүзләре бәгыренә таш булып утырды. Ачу ташы! Инде менә үсмер егет өстенә кияр киеме юкка үртәлеп ята. Ничек барсын клуб бакчасына бу киемнәре белән?

Таң ату белән, сыерларны көтүгә куа башладылар. Ишегалдында чиләк чылтыраганы, сыерлар мөгрәгәне ишетелә. Бабасы сыер сава. Чиләк төбенә зең-зең итеп сөт агып төшә…

Сәет урыныннан сикереп торды. Тиз генә капкалап алды да, чыбыркысын алып, көтү туплана торган тәшкә җыенды.

– Ник ул киемнәрең төрле якта җата? – диде Зариф карт, аптырап.

– Тузганнар.

– Ник, тузган әйберне тышка аталармыни?

– Кечерәйгәннәр.

Сәетнең бабасы белән дә сөйләшәсе килми. Кәефе юк. Чыбыркысын сөйрәп, сыерлар туплана торган урынга килгәндә, аны Хәния куып җитте, ул үзләренең сыерларын савып, көянтәчиләкләрен асып, сөт җыючы Шәяхмәт абзыйларга сөт илтә бара иде.

– Нихәл, Сәет, ник кичә клуб бакчасына чыкмадың? Көтеп торганыем, – диде Хәния, уңайсызланып кына.

– Чыгасы килмәде лә, арылды кичә, сыерлар артыннан чабып йөреп…

– Бик күңелле булды. Әгъләм бик матур итеп уйнады кичә. Бер дә ялындырып тормады. Зәйтүнәгә ошыйсы килде инде аның.

Сәет дәшмәде. Кичә кунак кызын кем озатканын бик беләсе килсә дә, сорап торасы итмәде.

Кояш Урыстау өстенә күтәрелә башлауга, малайлар сыерларны Ялантау ягына кудылар. Бер-ике сәгать кенә йоклап алган үсмерләр, авызларын ачып исни-исни, ялкау гына атладылар. Әгъләмнең нигәдер кәефе юк. Сәет күз кырые белән генә Әгъләмгә карап ала. Моңа нәрсә булган? Әгәр кичә Зәйтүнә белән борчаклары пешкән булса, очып йөрер иде. Димәк, кунак кызы моңа тәтемәгән!

Иртәнге салкынча һава үзенекен итте. Малайларга җан керә башлады. Алар бер-берсен үчекли-үчекли, шаярыша-көлешә, инеш буена килеп җиттеләр.

– Кара әле, Әгъләм, кичә Фатыйма түти табагач белән сыйлады мәллә үзеңне? Кунак кызын карата алмаганга, әлүн кагы капкан кебек кыланасың. Ату әле миңа бер кызның да каршы килгәне юк дип мактанган идең. Чирттеме борыныңа кунак кызы?

Әгъләм, каш астыннан гына Исмәгыйльгә карап, теш арасыннан җөмләсен сытып чыгарды.

– Телеңә салынып тор әле, торна тәре. Шушы ташка сылап куям хәзер. Тагын бер генә сүз әйт.

Ләкин үсмер малайларны туктатып булырдай түгел. Алар кичә Әгъләмнең Каракай әбиләр капка төбендә Зәйтүнәне тотып алуын, мондый тупаслыкны күрмәгән кызның кычкырып җибәрүен, Фатыйма түтинең, табагач күтәреп, Әгъләм артыннан куа киткәнен күргәннәр. Шуңа күрә Әгъләмнән әчләре катып көләләр. Берсеннән-берсе арттырып, малайны үчеклиләр.

Әгъләм малайларга карап торды да:

– Әгәр бүген бу кыз минем янда калмаса, исемем гармунчы Әгъләм булмасын. Кичә Фатыйма апа гына чыгып эшне бозды. Ул чыкмаган булса, бер үпмичә кайтып китми идем. Бүген капка төпләренә җиткәнче үк тотам мин ул кызыйны. Әйтте диярсез.

Сәетнең күңеле үсте. Вәйт Зәйтүнә! Булдырган! Юньле бала икән, дип, эчтән генә сөенде үсмер егет, эчтән генә үзе яраткан көйне көнозын көйләп йөрде:

Бишмәтеңдә синең биш төймә ләй,
Нигә төймәләймисең?

Болын кичәгегә караганда матуррак, чәчәкләр хуш ислерәк тоелды Сәеткә.

Әмма… Их, кайлардан гына чалбарлык акча табарга? Аяк киемен ямап кисәң дә була. Берәрсе акча биреп торса, күкәй сатып булса да түләр иде әле. Әллә инде Миңлебикә түтидән сорап торасы? Их, шул акча юклык үзәккә үтә. Ләкин яшьлек – яшьлек инде. Булыр әле, Алла бирсә, бары да булыр. Бер җае чыгар.

Кичен өйгә кайтып кергән Сәет өй эчендә кемнәрнеңдер мыдер-мыдер сөйләшкәнен ишетеп сагаеп калды. Фатыйма апа икән, хәл белергә килгән. Ишек төбендә Фатыйма апаның кызыл эчле галушлары янәшәсендә ап-ак туфлиләр. Кемнеке булыр бу? Сәет аңлап алды: Зәйтүнә!!! Үзе килгән. Сәет, өстендәге киемнәреннән оялып торса да, өйгә керәсе итте. Күпме качып йөрергә була! Ни булса шул. Өйгә кергәч, өйләрен танымыйча торды егет. Өй бу яхшы кешеләрдән төшкән нурдан балкып тора.

ӘСӘРНЕҢ ТУЛЫ ВАРИАНТЫ – САЙТТА

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Кәмит

Була бит инде шундый кешеләр, юморны аңламый торган. Берничек тә. Менә бу кешеләр юморны аңламый, ә юмор аларны аңлый. Һәм һәртөрле кызыклы хәлләр нәкъ менә шундый кешеләргә ияреп йөри.

Әнә шундыйрак бер таныш бар минем. Яхшы күңелле, әйбәт кеше. Тик җитди. Бик җитди. Ә кызык хәлләр үзенең билбавына ябышып йөри.

Яшь чагында ук әле... Бер кызга гашыйк була, йөри башлыйлар. Кыз әтисе белән генә яши. Әтисе бик еш командировкага китә. Үзе юкта күз-колак булып торырга күршеләрен ялый. Ну күршеләр тәкә инде. Подъезд алдында утырган әбиләрдән башлап, барысы да күз-колак була.

Вәт, бер мәлне әтисе командировкага китү белән кыз егеткә шалтырата. Егет килә. Тик сиздермичә генә фатирга үтү җае юк. Подъезд алдында утырган әби-чәби шундук әтисенә хәбәр итәчәк, әтисе кызны тиргәячәк. Фатирлары беренче каттa гына булгач, бу балкон аша керергә була.

Дәрте ташып торган егеткә авыр нәрсә түгел – керә бу. Кыз табын әзерләгән, бераз капкалап алалар... Шуннан кочаклашу... Кысыбрак кочаклашырга гына җыенып беткәч, ишектә кыңгырау чылтырый. Берәр күрше карчыгыдыр дип барып ачсалар, әй әчнә милиция кереп тула.

Бактисәң, егетнең балкон аша кергәнен бер карчык күреп калган икән. Моны карак дип уйлап, тәртип сакчыларын чакырган. Һәм әле дә: «Менә шушы карак», – дип басып тора. Өстәвенә күз дә йоммыйча: «Бу минем дә балконга кергән иде, бөтен чүпрәкләрне урлап качты», – ди. Ярый кыз сабыр булып чыга, барысын да тыныч кына аңлатып бирә. Шулай котылып калалар.

Өйләнешәләр болар. Бер-бер артлы кызлары туа. Әти-әниләре эштә чакта кызлар качышлы уйнарга күнегеп китә. Шкафка яшеренәләр. Әниләре кайтуга бөтен дөньяны туздырып бетерәләр. Көн саен. Моңа ничек чик куярга белмәгән әниләре хәйлә кора:

– Кызым, сез шкафка кермәгез, анда мыеклы усал абый бар, – дип кисәтә.

Кызлар чынлап та шкафны туздырмый башлый. Тынычланалар. Ә көннәрнең берендә җыелышып кичке табында утырганда, өлкәнрәк кызлары шыпырт кына сорап куя:

– Әни, ә шкафтагы теге мыеклы абый киттеме әле?

Ә ир җитди. Бу сүздән соң кара коелып төшә. Һәм хатынына бик озак, бик тырышып акланырга туры килә. Ләкин икенче көнне үк тагын котелмәгән хәл килеп чыга. Ничектер йолдызнамәләр турында сөйләшеп китәләр дә кызлары сорап куя:

– Әни, ә син кем йолдызнамә буенча?

– Кыз.

– Ә мин кем? Ә син бер хәрефен генә әйт, калганын үзем табам.

– К...

– Кысла! – Кыз кулларын кыскыч итеп суза. – Мин – кысла... Ә әти кем?

– Б...

– Болан! – ди кыз, шатланып, һәм кулларын тармаклы мөгез итеп баш өстенә куя. – Безнең әти – болан!

– Юк, кызым, болан түгел, ә балык... – Кичә генә шкафта мыеклы абый юклыгын исбатлап аптыраган хатын дулкынлана төшә. Ә кызга аның халәте мөһим түгел, аның үз уены – уен:

– Балык. Мөгезле балык, әйеме. Безнең әти – балык...

Ә ир җитди. Ул кара көеп хатынына бераз карап тора да ишекне шапылдатып чыгып китә. Ишегалдын әйләнеп килә дә подъезд алдында утырган әбиләр янына туктап, акрын гына сораштырмакчы була:

– Карале, безгә нинди мыеклы ир килгән иде ул?

Әбиләр бер-берсенә карашып ала. Әйтерлек бер сүзләре дә юк. Шунда берсе шаяртырга уйлый:

– Ә син баягы ирне әйтәсеңдер әле. Син чыгып китү белән кереп китте бит...

Ир шундук күздән югала. Йортына атылып керә. Бүлмәләрне, балконны, шкафларны тикшереп чыга. Билгеле инде, беркем дә юк. Шуннан бу бушап калган өстәл янына барып утыра. Җитди итеп уйлана, анализлый. Һәм берзаман шаркылдап көлеп җибәрә. Шатлыктан да, әлбәттә, әлеге күренешнең кәмитлеген аңлаудан да.



Рәис Габдулла

11 февраль санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: Циклоп, кимвал, Раймонд, трик, Луи, сеньор, анчар, боз, Киву, агылый, куныч, чыршы, пылау, шактый, Ан, тинтәк. **Вертикаль буенча:** цукат, ашык, Усы, Камри, чуан, вакса, гына, Ай, ергыч, ушат, пилмән, кычыткан, ниобий, ТНТ, Дуров, ышкы, зур, йөк.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 «Синең йөргән юлларыңда
Җиләкләрем түгелде.
Кырын каравыңны белгәч,
Күңелләрем сүрелде».
Бу шигырь юлларының авторы кем?
А) Рафаил Сибат;
Б) Илдар Юзеев;
В) Шәукәт Галиев.

2 Татарстан Президентын сайлау беренче тапкыр кайчан уза?
А) 1991 ел, 26 декабрь;
Б) 1991 ел, 12 июнь;
В) 1992 ел, 30 ноябрь.

3 Татарстан АССРның беренче байрагы нинди төстә була?
А) байрагы булмый;
Б) ак;
В) кызыл.

4 Дирһәм ул – ...
А) Шәрык кемеш тәңкәсе;
Б) Казан ханбикәсе;
В) борынгы дин.

Җаваплар: 1) Б; 2) Б; 3) В; 4) А.

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 17126 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 224

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+